«Өлкәннәр бездән тәмле сүз көтә»

Ялгыз карт-коры, авыру инвалидларның йорт эшләрендәге иң беренче ярдәмчеләре дә, сердәшче-киңәшчеләре дә – социаль хезмәткәрләр. Казанның Авиатөзелеш районының халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгендә 22 ел эшләүче Ирина Пименованың да гаиләсе ишле – ул 13 кешегә ярдәм итә.

5 БИТ

Ярый әле Тукай туган

Ярый әле Тукай туган. Чөнки бу көнне һава торышы нинди генә булса да, үзен азмы-күпме зыялы дип санаган һәркем вакытын табып, бар эшен читкә куеп, Тукай янына килә һәм үзенең гамәл сәгатен Тукай сәгате белән дөресли. Бу көнне Тукай безгә бик күп сабак-дәрес бирә.

4 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 28.04.2017 | № 46 (5808)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ЭКОЛОГИЯ СӘГАТЕ: ДӘРЕСЛЕКТӘ ТҮГЕЛ, ГАМӘЛДӘ

Балага, тәпи йөри башлаганда ук, экологик тәрбия бирергә кирәк дигән фикердә Казанның 100нче урта һөнәри белем бирү мәктәбе укытучылары. Шуңа да математика, татар теле, әдәбият кебек фәннәр белән беррәттән укучыларны табигатьне сакларга да өйрәтә алар. Дәресләрдә экологик темага багышланган диктантлар язылa, рәсем, плакатлар ясала. Балалар алган белемнәрен исә табигатьтә сыный. Кар эрегәнен генә көтеп торалар.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Алисә САБИРОВА

27 апрель көнне дә I-XI сыйныф укучылары мөгаллимнәре белән зур өмә оештырды. Мондый өмәләр ел әйләнәсендә берничә була, аеруча яз-көз көннәрендә ешая.

– Мәктәп ачылганнан бирле буыннан буынга күчеп килгән бер матур гадәт ул безнең. Мәктәп янында ике урман, бер күл бар, аларның чисталыгы – барысы да безнең күзәтү астында. Ә өмәгә чыгу – укучыларның үз теләге. Аларга табигать сагында торырга укытучылар, ата-аналар, районның мәгариф бүлеге ярдәм итә, – диде 100нче мәктәпнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Наталия Корнеева.

Яшь экологлар узган ел «Парклар маршы» чарасында да катнашкан. Быел «100 яшел почмак» дигән акциягә дә кушылган. Бер сүз белән әйткәндә, бик актив алар. Өмәдә балалар олыга-кечегә бүленми генә, барысы бер булып, кар астыннан чыккан чүпне чистартты. Аларның ярдәме белән, мәктәп артында чыршы, нарат агачларыннан торган матур бер урман үсеп килә. Бу агачларны укучылар үзләре утырткан.

– Өмә оештыру һәр яктан файдалы гына. Балалар хезмәт белән тәрбияләнеп үсә, экологик тәрбия ала, әхлакый кыйммәтләргә өйрәнә, ватанны, табигатьне ярата башлый. Саф һавада эшләү сәламәтлек өчен дә файдалы бит. Бер сүз белән әйткәндә, бездә экологик тәрбия теориядә генә түгел, ә гамәлдә, – диде Наталия Корнеева.

Өмәгә килгән Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы вәкилләре укучыларга 29 апрель көнне булачак #ЭКОяз2017 чарасына флаерлар тапшырды. Балалар бу кәгазьләрне велосипед яки турист палаткасына алыштыра ала.

Мәктәп укучылары гына түгел, ә теләгән һәр кеше әлеге экологик хәрәкәттә катнашырга мөмкин. Моның өчен яшәгән шәһәреңне, районыңны җыештырырга, чүплектән азат итәргә булышырга кирәк. Өмә булачагын үз яныгыздагы территориаль идарәгә дә хәбәр итәргә онытмагыз.

Иртәгә шулай ук «Яшел Россия» дигән ил күләмендә оештырылган зур өмә булачак. Чарада Татарстанның барлык шәһәрләре катнаша. Меңләгән республика халкы әйләнә-тирәне чүплектән арындырып, агачлар, чәчәкләр утыртачак. Кәгазь, пыяла, пластик шешәләр кебек чүпләрне аерып җыячаклар.

«Бу ел республика өчен уңышлы булачак»

Мәскәүдә узган очрашуда Рөстәм Миңнеханов Россия Президенты Владимир Путин белән Татарстанның социаль-икътисади хәле, уңышлары, проблемалары турында сөйләште. Владимир Путин Татарстанның күп параметрлар буенча алдынгы рәттә торуын билгеләп узды. Шул ук вакытта кайбер катлаулы мәсьәләләр чишелеш көтә.

kremlin.ru

Беренче чиратта Рөстәм Миңнеханов, Минтимер Шәймиевнең Россия Хезмәт Герое исеменә ия булуы уңаеннан, Владимир Путинга барлык республика халкы исеменнән рәхмәт сүзләрен җиткерде.

– Бу лаеклы исем – безнең республика өчен дә зур бүләк. Алга таба да Россия Федерациясе белән зур проектларны бергә гамәлгә ашырып, ил өчен файда китерербез дип уйлыйм, – диде ул.

Бу бүләкне алган кешеләр арасында Минтимер Шәймиев – татарлардан икенче һәм төбәк башлыклары арасында беренче булуы белән дә үзенчәлекле.

Соңрак җитәкчеләр илнең социаль-икътисади хәле хакында сөйләшүгә күчтеләр, дип хәбәр итә Татарстан Президенты матбугат хезмәте. Рөстәм Миңнеханов былтыргы вазгыять һәм 2017 елның 1 кварталына икътисади торыш буенча хисап биргән.

– Берничә санны атап китәсем килә. 2016 елда сәнәгать җитештеру индексы 103,6 процентны тәшкил итте. Тулаем төбәк продукты – 102,5 процент. Төп капиталга инвестиция, авыллар, торак төзелеше – май указлары белән билгеләнгән төп бурычларның берсе. һәм алар барысы да тормышка ашырылып килә. Быелның беренче кварталы буенча сәнәгать продукциясе – 104,7 процентка, ә тулаем төбәк продукты 104,2 процентка үсте. Җыеп әйткәндә, илнең икътисади хәле тотрыклылана, республикада 30лап дәүләт программасы уңышлы эшләп килә, – дигән Рөстәм Миңнеханов.

Сырхауханәләрне төзекләндерүгә юнәлтелгән ике еллык программаны да искәртми мөмкин түгел. Россия Президентының Федераль Җыенына еллык юлламасында да бу йөкләмә мөһимнәрдән булып яңгыраган иде. Рөстәм Миңнеханов та Татарстанда әлеге программа кабул ителүе хакында Владимир Путинга җиткерде. «Ике ел дәвамында 180ләп беренчел звено медицина объекты яңартылачак», – диде.

Республиканың Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хәбәр иткәнчә, Татарстанда банкротлыкка чыккан банкларның 2036 хезмәткәре эшсез калачак. Банклар – бүген республиканың иң авырткан урыны, мөгаен. Рөстәм Миңнеханов та банклар белән бәйле вазгыятьне мөһим проблемаларның берсе дип атады.

– Берничә банк банкротлыкка чыкты. Шактый кертемчеләр акчаларын югатты. Аларга ярдәм йөзеннән, хөкүмәт тарафыннан махсус комиссия төзелде. Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы, Үзәк банк белән дә актив эшлибез. Хәзер кредитор массасын формалаштыру процессы бара. Гаепләләр тоткарланды, хокук саклау органнары бу эшне тикшерә. Әлбәттә, әлеге мәсьәләдә берәр механизм уйлап табарга кирәк: без махсус фонд булдырып, үз кертемнәрен кайтара алмаган клиентлар өчен нинди дә булса мөмкинлекләр тудырырга тырышабыз, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты әйтүенчә, өлешләп түләүчеләргә кагылышлы чишәсе мәсьәләләр дә җитәрлек. Бу өлкәдә шулай ук ныклы эш алып барыла. Ике зур компаниянең җитәкчесе кулга алынган.

Очрашу азагында Рөстәм Миңнеханов бу елның да республика өчен уңышлы булачагын ышанып әйтте. Шулай була күрсен.

СӘЯСӘТ

Фәрит Мөхәммәтшинга «Кызыл китап» бүләк иттеләр

Дәүләт Советында кичә «Татарстан – новый век» – «Татарстан – яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәтенең политсоветы утырышы булды.

Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үзенең кереш сүзен Татарстан халыкларының III съездын искә төшереп башлады.

– Татарстанда 173 милләт һәм халык вәкилләре яши. Алар съездга милли киемнәреннән килделәр, күпләр, һич кыенсынмыйча, орден-медальләрен таккан. Зал төрле бизәкләрдән матур булып балкып торды, – дип, халыкларның бердәмлегенә әһәмият бирде республика парламенты рәисе.

Ул вазгыятьнең шактый җитди булуын да яшермәде.

– Кризис дәвам итүен, санкцияләр һәм антисанкцияләр хөкем сөрүен без белеп торырга тиеш. Озак вакытларга исәпләнелгән инвестицияләр керми, технологияләргә юл ябык. Татарстандагы банк кризисы да өстәлде, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Татарстанда социаль юнәлешле 34 программа гамәлгә ашырыла. Дәүләт Советы рәисе социаль программаларның дәвам иттереләчәген ышандырды.

Политсовет «Татарстан – яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәтенең VII съездын үткәрүне быелның 31 маена билгеләде. «Татарстан-яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәте политсоветы башкарма комитеты рәисе Алсу Тарханова таныштырганча, съездда «Политсовет» төшенчәсен «Югары Совет» («Высший Совет») сүзенә алмаштыру, Уставка кайбер башка үзгәрешләр кертү мәсьәләләре дә каралачак.

– «Татарстан-яңа гасыр» иҗтимагый хәрәкәте оешканга инде 18 ел. Бу – сәяси оешма түгел, ә җәмәгать оешмасы, шунлыктан «политсовет» сүзе мәгънәви яктан туры килми, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин быел Россиядә Экология елы булуын искәртеп, экологияне саклауга юнәлтелгән чараларның мөһимлегенә басым ясады. Политсовет утырышында Татарстандагы табигать тыюлыклары мәсьәләсе каралды. Идел-Кама дәүләт табигать тыюлыгы директоры Юрий Горшков чыгышында әйтелгәнчә, Идел-Кама дәүләт табигать тыюлыгы 1960 елда оештырылган. Әлеге тыюлыкка караган Раифа урманы – үзе бер могҗиза.

Юрий Горшков Татарстанның «Кызыл китабын» Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга бүләк итте һәм тыюлыкның координация советы рәисе булырга чакырды. Фәрит Мөхәммәтшин: «Мин инде болай да бик күп җәмәгать оешмаларында катнашам. Өлгереп җитеп булмый», – дип, әле уйлаячагын әйтте.

Дамир БӘДРИЕВ.

gossov.tatarstan.ru

Ата-аналарга ярдәм

Балалары булган гражданнарга нинди социаль ярдәм каралган. 3 май көнне «Бердәм Россия» сәяси партиясе рәисе Дмитрий Медведевның Татарстандагы төбәкара иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә әнә шул хакта сөйләшәчәкләр.

Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова, Төбәкара иҗтимагый кабул итү җитәкчесе, Дәүләт Советы депутаты, «Россиядә һәр бала мөһим» партия проекты җитәкчесе Татьяна Воропаева белән берлектә халыкны кызыксындырган сорауларга җавап бирәчәк.

Кабул итү Карл Маркс урамы, 31/7 йорт адресы буенча сәгать 10.00дән 13.00гә кадәр дәвам итәчәк. Очрашуга **(843) 238-10-00** номеры аша алдан да язылырга була.

Җимерек йортларны онытырга вакыт

Чистайда авария хәлендәге йортларда яшәүчеләр яңа торакларга күченделәр. Бу чарада Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фондының күзәтчелек советы рәисе Сергей Степашин, Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт Торак фонды башкаручы директоры Тәлгать Абдуллин, республиканың төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры Ирек Фәйзуллин да катнашты. Сергей Степашин авария хәлендәге тораклардан күчерү программасын уникаль дип атады.



Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Татарстанда 2017 елның 1 сентябренә 749 кешене җимерек йортлардан күчерергә җыеналар. Бу максатларда республикада 65 йорт төзелеп килә.

– Мондый программа Советлар Союзында, Россиядә беркайчан да булмады. Дәүләтнең моңа алынуы бик мөһим. Яңа фатир ачкычларын бүген алучылар, аңа кадәр торакларга күченүчеләр дә моңа лаеклы. Бараклардагы яшәү шартлары турында ишетеп кенә түгел, үзем күргәннәрдән чыгып та беләм, – диде чыгышында Сергей Степашин.

Чистайда Федераль программа буенча төзелгән йорттан 244 кешегә фатир ачкычлары тапшырылды. Июль аена бараклар урыны төзекләндерелеп бетәргә тиеш. Әгәр эш кирәгенчә башкарылмаса, Сергей Степашин үзенә шалтыратырга кушты. Бу мәсьәләне тикшереп барачагын да искәртте.

Аның әйтүенчә, 5 май көнне Федерация Советы утырышында авария хәлендәге тораклардан күчерү программасын озайтырлар, мөгаен. Чөнки җимерек йортлар саны кимеми. Сентябрьгә 1 миллион кеше бараклардан күченер дип фаразлана. Әмма менә Татарстанда программаны көзгә үк төгәлләргә ниятлиләр. Бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та искәрткән иде. 11 мартта Министрлар Кабинетында узган утырышта ул:

– Программаны тагын ике елга озайту берни бирми. Безнең графиклар билгеләнгән. Барлык юридик процедураны узарга кирәк. Ходай өчен, әйдәгез бу эшне ахырына җиткерик. Барлык карарларны кабул итеп, бу теманы ябыйк, – дигән иде.

Сергей Степашин да, Татарстан авария хәлендәге торакларның нәрсә икәнен онытырга тиеш, дип белдерә.

Татарстанда төзелеш буенча 36 дәүләт программасы эшләп килә. Тиздән тузган сырхауханәләрне ремонтларга тотыначаклар.

28-29 апрель көннәрендә Казанда ишетмәүчеләр арасында DeafSkills I халыкара һөнәри осталык ярышлары була. Яшь белгечләр ун юнәлештә, шул исәптән химик анализ, фото сәнгате, аш-су осталыгы, чәчтараш, агач остасы кебек һөнәрләр буенча көч сынаша.

Ишетмәү киртә булмаска тиеш

Бүген Татарстанда 6 мең кеше начар ишетә яисә бөтенләй ишетми. Шуларның бары 32 проценты (1920 кеше) гына рәсми рәвештә эшкә урнашкан. Ишетмәсәләр дә, аларның җәмгыятькә файдалы буласы килә.

– Кызганыч, бүген начар ишетүчеләр тулы канлы тормыш белән яши алмый. Бу – зур проблема. Без башкалар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтебез белән кешелеккә файда китерә, үз эшебезнең остасы була алабыз. Бу омтылышларыбызның башлангычы булып Казан торачак. Файда китерә алуыбызны бар дөньяга дәлиллисе килә, – диде DeafSkills Халыкара ассоциация президенты, Бөтендөнья ишетмәүчеләр оешмасы вице-президенты Станислав Иванов.

DeafSkills ассоциациясе 2016 елның мартында Россия теләктәшлеге буенча оеша. Аның максаты – ишетмәүчеләрнең сәләтен барлау, тормышта үзләрен табарга ярдәм итү, эшкә урнаштыру.

– Сәламәт яшьләр арасында «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионаты үткәрелә. Мөмкинлекләре чикләр өчен дә «Абилимпикс» дигән бәйгеләр бар. Мондый төр чемпионатлар – эшчеләргә үз осталыгын күрсәтү, сыйфатлы белем алу, эшкә урнашу мөмкинлеге. Ләкин бу ярышларның берсендә дә ишетмәүчеләр катнаша алмый. Алар эшкә дә урнаша алмый интегә. Бүген без менә шул проблемаларны хәл итәбез, – диде Станислав Иванов.

Чемпионатта яшьләр ярышып кына калмый, биредә ишетмәүчеләр өчен эш тә тәкъдим итәчәкләр әле. Эш бирүчеләр, эшмәкәрләр дә ярыш барышын күзәтәчәк. Бүгеннән Бөтендөнья ишетмәүчеләр федерациясе белән DeafSkills халыкара ассоциациясе үзара хезмәттәшлек итәчәк. Дуслыкларын алар ике яклы килешү ярдәмендә теркәде.

Эшче яшьләр Казан төзелеш көллиятендә җыела. Биредә Мәскәү, Свердловск өлкәсе, Удмуртия белән Башкортстаннан 49 белгеч, 39 эксперт катнаша. Беренче зур чара бүген булачак.

Студент балаң булса, пенсияң арта

Балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче пенсионерларның, шулай ук студент баласы булган әти-әниләрнең пенсиясе арта.

Бу очракта иминият пенсиясенә фиксацияләнгән түләү арттырылып бирелә. Бер бала өчен әтисе дә, әнисе дә пенсиягә өстәмә түләү алырга хаклы. Әмма бу түләүләр иң күбе өч бала өчен түләнә.

Әлеге өстәмә түләүләрне алу өчен, теркәлү урыны буенча пенсия бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Үзең белән балаларның туу турындагы таныклыклары, 18 яшьтән узганнарның уку йортында белем алуы турында белешмә дә сорала. Өстәмә түләүнең тәгәл суммасын пенсия бүлеге хезмәткәрләре исәпләп бирәчәк.

– Балигъ булмаган балалардан тыш, студент балалары булган пенсионерлар да гадәттәгедән зуррак суммада фиксацияләнгән түләүләр алырга хокуклы. Моның өчен баланың көндезге бүлектә укуы шарт, түләүләр укуны төгәлләгәнче бирелә, шулай да балага 23 яшь икән, түләүләр туктатыла, – ди Россия Пенсия фондының Татарстан идарәсе җитәкчесе Эдуард Вафин.

Шулай ук студент укуын ташлаганда, озак вакытка академик ял алганда яки хәрби хезмәткә киткәндә дә түләүләр бетерелә.

Кирәкмәгән сабыйлар күбәя

Әле күптән түгел генә Чаллыда Кама балалар медицина үзәгендә ачылган бэби-бокста беренче ташландык сабый куелуын ишетеп ачынган идек.

Быелның 27 гыйнварында әлеге тартмага (ул беркемгә дә кирәге булмаган, ләкин дөньяга килгән нарасыйларның гомерен саклап калу өчен махсус уйлап табылган) куеп калдырылган кызчык бүген сау-сәламәт, яңа әти-әнисе белән яшәп үсеп ята.

25 апрель көнне Чаллыдан тагын бер шундый хәбәр килде. Шул ук үзәктән ерак түгел, дөресрәге, аның чүп савытлары янәннан үтеп баручы бер ир кеше кечкенә сигезенче яртылар тирәсендә нәни бала еланганы ишетеп ала. Тавышның хуҗасы – «тере төргәк» тә ерак булмый. Әлеге сизгер ир-ат полиция чакырта. Табиблар ныклап тикшергәннән соң, кызчыкның исән-сау булуын, аның сәламәтлегенә бернинди дә куркыныч янамавын әйтәләр. Бәхеткә, нарасый язгы салкын җирдә озак ятмаган булып чыга. Ташлап калдырыр алдыннан аңа матур яңа киемнәр кигезгәннәр, әйбәтләп төргәннәр. Ләкин монда башка сыймаслык бер нәрсә бар. Бала табылган урыннан ерак та түгел 300-400 метрда гына бэби-бокс урнашкан. Яшь әни тугыз ай буе йөрәге астында йөрткән нарасыен нигә шунда куеп калдырмады икән? Бу сорау күке-ананың кем булуын ачыклаганчы җавапсыз калып тора.

БЕЛЕП ТОР!

Май бәйрәмнәренә өстәмә транспорт

«Южный» автовокзалында 28-29 апрельләрдә Нурлат, Чистай, Түбән Кама, Тольятти, Базарлы Матак, Болгар һәм Чирмешән юнәлешләренә өстәмә автобуслар билгеләнде.

«Восточный» автовокзалында 28-29 апрельләрдә, шулай ук 3, 5, 6 май көннәрендә Чаллы, Актаныш, Менделеев һәм Минзәлә юнәлешләрендә өстәмә автобус рейслары булачак.

Җәйге навигация ачыла

Казан елга портында һәм Чаллы елга портында 30 апрельдә 2017 ел җәйге навигация ачыла. Автобус һәм елга суднолары рейсларының расписаниесе белән автовокзаллар һәм елга портларының интернет сайтларыннан танышырга була.

ЯРЫЙ ӘЛЕ ТУКАЙ ТУГАН

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

БӘЙРӘМ КАЙТАВАЗЫ

Мәдинә Маликова:

– Татар халкы авыр елларда да, акыллы, зирәк, алдан күрүчән җитәкчеләр аркасында, җиңеп чыкты. Бу – халыкның зур казанышы. Канкоешлар, сугышлар булды, әмма безнең халкыбыз моңа дучар ителмәде. Сират күперennән чыккандай алып чыктылар безне. Хәзерге вакытта Казаныбыз дөньядагы иң матур шәһәрләрдән санала. Республика даны еракларга таралды. Бу үзгәрешләрдә мин үземнең дә өлешем бар дип саныйм. Чөнки милләтне иң беренче чиратта милли әдәбият һәм сәнгать үстерә.

Харис хәзрәт Салихов:

– Элек дин дәүләттән аерылган иде. Дин дәүләттән аерылган булса да, җәмгыятьтән аерылмады. Хакимиятнең кешеләрне тәрбияләүнең иң асыл юлы – диннең фән белән бергәлеге таныту. Динне мәктәпләргә кертергә кирәк. Шул чакта гына тәүфыйклы буын үсәр. Безнең карамакта 35 ятим бала бар. Дәүләт премиясеннән килгән акчаны бу балаларга бүлеп бирәчәкбез, алар аңа ныграк мохтаҗ.

Розалина Шаһиева:

– Буләктән дә бигрәк, ватаным, телем, мәдәният һәм шигърият кадерле.

Язмышның ялгышы аркасында Тукай дөньяга килми калган яки сабый чакта ук вафат булган булса, милләтебезнең рухы күпкә ярлырак булыр иде. Бик күп әдәби әсәрләр, картиналар, көйләр язылмый, фәнни ачышлар ясалмый калган булыр иде.

Яз җитүгә, милләтебезне Тукайлы иткәне өчен, күңелдә бөек Илаһка рәхмәт хисләре бөреләнә. Тукай безгә яз саен кайта да кыш буе күшеккән җаннарыбызны җылытырга керешә. Үз милләтенең генә түгел, шигърияткә гашыйк, әдәбиятны яраткан һәркемнеке ул Тукай. Милләтенә, диненә карамастан, ул бүген дә һәркайсыбызны үз тирәсенә туплый. Татарстаныбызда йөздән артык милләт халкы дус-тату яши икән, монда да Тукаебызның роле зур. Моны илебез җитәкчеләре дә көннән-көн яхшырак аңлый. Быел да шагыйрьнең туган көн иртәсендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе – әле яңа гына Россиянең Хезмәт Герое исеме бирелгән Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Тукай һәйкәленә чәчәкләр салырга килде. Алар артыннан олысы-кечесе тоташ агым булып агылды.

Тукай һәйкәле, чын-чынлап, татар халкын бергә туплый торган бер мәккәгә әйләнеп калды. Бөек шагыйрьне олылап кайлардан гына килмәгәннәр. Башкортстанның Кыйгы районыннан бер төркем укучылар, укытучылар һәм шигырь яратучылар махсус шушы көнгә туры китереп Казанга килгәннәр. Аларны якташлары шагыйрә Резеда апа Вәлиева белән дә кызыклы очрашу көтә. Тукайга чәчәк китерүчеләр арасында Красноярск, Баку һәм Россиянең күп кенә төбәкләреннән килгән милләттәшләребез дә бар иде.

Тукайның тууына 131 ел тулуга багышланган Туган тел бәйрәме Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында дәвам итте. Бәйрәмнең башында ук Рөстәм Миңнеханов Тукай бүләгенең быелгы бәхетле ияләрен игълан итеп, аларны чын күңелдән котлады. Алар – Мәдинә Маликова «Арыш тәме: роман, повесть, хатирәләр» (Казан: «Ихлас» ЖЧЖ, 2014); Харис Салихов «Александр Пушкин, Габдулла Тукай иҗатында дөньяви һәм дини мотивлар һәм бүгенге көндә әхлакый тәрбия бирү проблемалары» (Казан, «Идел-Пресс» нәшрияты, 2008); «Дин һәм фән (дөньядагы дини һәм дөньяви мәдәният нигезләре)» (Казан, «Идел-Пресс» нәшрияты, 2012), Розалина Шаһиева Татарстанның милли мәдәни мирасы турындагы «Мәңгелек гөлчәчәкләре: татар һәм рус телендәге мәкаләләр җыелмасы» (Казан: «Заман» нәшрияты, 2015) өчен лаек булдылар. Зал аларны озак алкышлады. Тантанадан соң кемнән генә сорасаң да, быелгы лауреатлар бик хак сайланган, диган фикерне ишетергә туры килде. Чөнки алар өчесе дә – милләтебезгә, әдәбият-сәнгатебезгә һәм дин-әхлагыбызга хезмәт итүгә гомерләрен багышлаган, рухыбыз сагында торган олы шәхесләр. Мәдинә Маликованың быел беренче китабы дөнья күрүгә ярты гасыр булган. Ә Харис хәзрәт – 90 яшен тутырган аксакал. Розалина ханымның да мәшһүр сәнгать белгече һәм зур шагыйрә булarak белә халык. Күрәсең, бу гадел карарга Тукай үзе дә, аның рухы да шатлангандыр. Көне буе күктә кояш елмайды. Көне дә матур, күңелләрдә дә ниндидер бер күтәрелеш, рух күтәрелеше. Ә бит башка елларда без: «Тукай да туңган, без дә өшибез», – дип, үзәкләргә үтәрлек салкын көннәрдә дә мәйданнан китмичә тыңлый идек шигырьне.

Безнең Тукаебызны олылап, һәр елдагыча, төрле җирләрдән: Башкортстан, Мари Эл, Удмуртия, Кырымнан да шагыйрьләр килгән. Алар да үз телләрендә Тукайны зурладылар. Мәгънәсе бик үк аңлашылып бетмәсә дә, алар чыгыш ясаганда, Тукайлы татарның бер вәкиле булудан туган горурлык хисе бермә-бер артты. Заманыбызның танылган шагыйрьләре, Тукай бүләге ияләренең дә халыкка әйтер сүзләре саллы яңгырады.

Ярый әле Тукай туган. Чөнки бу көнне һава торышы нинди генә булса да, үзен азмы-күпме зыялы дип санаган һәркем, вакытын табып, бар эшен читкә куеп, Тукай янына килә һәм үзенең гамәл сәгатен Тукай сәгате белән дөресли. Бу көнне Тукай безгә бик күп сабак-дәрес бирә. Әлеге сабакны алырга яшьләрнең, мәктәп укучыларының да килүе аеруча сөендерә. Алдагы көнне башкалабыз күгендә быелның беренче салават күпере дә күренгән иде. Үзе яраткан, җан аткан халкына Тукайның фатихасы, Татарстаныбызның, милләтебезнең эшләре алга китүгә матур бер фал булды бугай ул. Нишләптер, күңелнең шулай дип ышанасы килә.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Мин татарча сөйләшәм, син дә сөйләш

«Мин татарча сөйләшәм» акциясе быел 12нче тапкыр үткәрелде. Бәйрәмгә килүчеләрнең күбесе архитекторлар арасында барган бәйгедә җиңү яулаган өч метрлы «Ә» хәрефе янында фотога төшмичә, милли ризыклардан авыз итмичә, милли рухта эшләнгән сувенирлар алмыйча китмәгәндер.

«Мин татарча сөйләшәм» быел да гадәттәгечә олы бер бәйрәм буларак, музыкаль чыгышлар белән үрелеп барды, уеннар да тәкъдим ителде. Чарага дәррәү булып килсәләр дә, тамашачылар арасында ниндидер пассивлык та юк түгел иде. Алып баручы Нурбәк Батулла аларны «кыздырырга», «ә» авазын кычкырыбрак әйттерергә шактый тырышты. Уеннарда актив катнашучыларга эмблемалы футболкалар да эләкте. Ничек кенә булмасын, яшьләрнең бу чараны көтеп алуы күңелле фал. Арада үзара рус телендә аралашучылар булса да, аларның татарча сөйләшүчеләр сафында булуы инде начар түгел. Ана теле, әби-бабаларыбыз теленә якынрак булу теләге дип карарга кирәктер моны. Кем белә, икенче килүендә бәлкем ул да, «Мин татарча сөйләшәм» дип чатнатып, үз телебездә аралаша башлаган булыр. Һәрхәлдә, шуңа өметләник. Тамырларыбызның ныклыгын сыный торган мондый чаралар дәвамлы булсын.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

«Өлкәннәр бездән тәмле сүз көтә»

Күзгә артыгын бәрелмичә, тыныч кына үз эшләрен намус белән башкаручы һөнәр ияләре була. Әнә шундыйлар рәтенә социаль хезмәткәрләрне дә кертергә мөмкин. Ялгыз карт-коры, авыру инвалидларның йорт эшләрендәге иң беренче ярдәмчеләре дә, сердәшче-киңәшчеләре дә алар. Казанның Авиатөзелеш районының халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгендә 22 ел эшләүче Ирина Пименованың да гаиләсе ишле – ул 13 кешегә ярдәм итә. Шуларның иң өлкәненә 91 яшь булса, иң яшенә – I группа инвалид ир-атка – 48 яшь. Ирина Юрьевна, кирәк икән, ашарга хәстәрли, өйләрен җыештыра, кибеткә, даруханәгә бара, түләүләрен түли, кан басымнарын үлчи, табиб чакырта, хәтта уколын ясарга да тартынып тормый.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Без картлар һәм инвалидлар белән эшлибез, ә аларга аеруча зур игътибар һәм ягымлы йөз, тәмле сүз кирәк. Без исә аларның һәрберсенә тел ачкычлары табабыз. Берничә ел яннарына килеп йөргәч, мине якын туганнары кебек каршы алалар. Әмма якын кешегә әйләнгәч, таләпләр дә арта. Картлар бит алар сабый бала кебек. Менә, мәсәлән, гомере буе җитәкче урыннарда эшләгән бер әбием бар. Холкы бик үзенчәлекле. Кызуланып, ачуланып ата да, аннан соң суына, гафу үтенә. Шул вакытта каты бәрелмичә, сүз дәшми генә түзәргә туры килә. Әмма мин үз тормышымны алардан башка күз алдына китерә алмыйм инде. Барысына да ияләшенгән. Кызым мине кайвакыт: «Син ул әбибабайларыңны безгә караганда да яхшырак беләсең», – дип, шаярту катыш шелтәләп ала, – ди Ирина Юрьевна.

– 22 ел дәвамында социаль хезмәткәр булып эшләү өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк соң? – дим мин дә, сөйләшүне дәвам итеп.

– Безнең эш зур җаваплылык, игътибарлылык һәм төгәллек таләп итә. Озаграк килми торсаң, картларның кәефләре төшә, борчыла башлыйлар. 20 ел дәвамында хезмәт күрсәткән бер әбием бар иде. 91 яше тулгач, балалары үз яннарына алды. Аңа бик ияләшкән идем, – ди яңа танышым.

Ирина Пименованың эше картларның йорт ишекләрен ябып чыгу белән генә бетми әле. Калганы өенә ияреп кайта.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

– Картларның гына түгел, аларның туганнарының да телефон номерлары бар миндә, чөнки ул-бу була калганда, өлкәннәр һәрвакыт диярлек беренче чиратта миңа шалтыраталар. Шундый вакытта нәрсә эшләргә кирәклеген туганнары белән бергәләп хәл итәбез. Бер клиентым, мәсәлән, һәр кич шалтыратып, тыныч йокы теләвемне үтенә. Балалары Мәскәүдә яши, үлеп китәрмен дә беркем белми калыр, дип курка. Шул рәвешле, исәнлеген белгертәсе килә. Шулай да мин картларны япа-ялгызлар дип әйтмәс иде. Алар бик аралашучан халык. Һәрберсенең телефоны бар. Ахирәтләре, чордашлары, күршеләре белән аралашалар, – ди ул.

КИҢ КҮҢЕЛ

Татарстанның Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре республиканың һәр районында бар. Аларда өйгә килеп хезмәт күрсәтү бүлекләре дә эшли. Агымдагы елның беренче кварталында мондый хезмәттән 15 мең кеше файдаланган, шуларның 1,8 меңе Казанда яши. Апрель башында яңартылган статистика мәгълүматлары буенча, хәзерге вакытта 14 мең кешегә социаль хезмәт күрсәтелә, шуларның якынча 1,7 меңе башкалада яши.

Озак еллар дәвамында өлкәннәребезгә ярдәм итеп килгән, аларның тормышларын якыннан белгән, нинди проблемалар борчыганын кешедән ишетеп кенә түгел, ә үз күзләре белән күргән кеше буларак, Ирина Пименованың башкаларга җиткерәсе теләкләре дә бар.

– Туганнары да картларга игътибарлырак булсыннар иде. Без аларга ярдәм итүче генә булырга тиеш. Әмма күп вакыт киресенчә кабул ителә. Менә шул күренеш күңелне бик әрнетә, – ди ул.

ЯЗМЫШ

Хәлең ничек, Миңлегөл апа?

Заманында Миңлегөл Рәфыйкованың исеме матбугат битләреннән төшмәде. Халкыбызның яраткан язучысы Фәнис Яруллин да « Яралы язмышлар» китабын аңа багышлап язган иде. Үземә дә, балалар йортына барып танышканнан соң, аның белән озак еллар аралашып яшәргә туры килде.

Бернинди педагог белеме булмаган гаҗәеп мәрхәмәтле, изге күңелле тәрбияче иде ул. Балалар аның тирәсендә үз әниләре янындагы сыман бөтерелеп йөрде. Ул аларның һәркайсының холык-фигылен белде, җылы карашын кызганмады. Ял көннәрендә балаларны өенә алып кайтып, аларга гаилә җылысы бирергә тырышты тәрбияче апалары. Үзенең дә ике улы бар иде. Үзләре исән була торып та, балаларының язмышы өчен борчылмаган ата-аналарга шакката иде Миңлегөл апа. Сабыйларның һәркайсы, аны яратып, «әни» дип эндәшсәләр дә, ул «әби» дияргә куша иде. Монннан 20 еллар чамасы элек үзе тәрбияләгән балаларны җиде ят җиргә – Америкага җибәрәселәрен ишеткәч тә бик кайгырды. Поездга утырып киткән чакта, аларның аерылырга теләмичә, вагон тәрәзәләренә ябышып, үрсәләнә-үрсәләнә елаганнарын ишетеп, йөрәге әрнеп йөрде. Җитмәсә, балалар белән тиз генә аралаштырмадылар. Ул аларның кесәләренә үзенең адресын да язып салган була. Лилия, Ванялар Лела, Даниэлларга әйләнеп беткәч, туган телләрен оныткач кына интернет аша хатлар языша башладылар. Әле дә хәтеремдә, Миңлегөл апа, тәрҗемәче таба алмагач, шул балалардан килгән хатларны тотып, редакциябезгә дә килгән иде. Шул чагында инглиз теле укытучыларына мөрәҗәгать итәргә киңәш бирдек. Аңа хатлар алышырга 2нче татар гимназиясе директоры Камәрия Хәмидуллина белән инглиз теле укытучылары ярдәмгә килделәр.

Балаларының чакыруы буенча, Миңлегөл апа Америкага да барып, аларның тормышлары белән танышып кайтты. Очрашу шатлыкларын безнең белән дә уртаклашкан иде. Әмма аларның рус телен бөтенләй онытуларына борчылып та кайткан иде. Иң аптырашта калдырганы мәктәптә балаларның: «Нигә сезнең илдә ятим балаларны аерым йортка җыеп тәрбиялиләр?» – дип соравы булган. Әмма әби кеше аңа җавап кына таба алмаган. Миңлегөл апа ул балаларның туган якларын кайтып күрүләренә өметен җуймады. Кайберләре аннан үз әтиәниләренең исемнәрен, кайсы районнан булуларын сораштырып, язып та алып калган бит.

Миңлегөл апаны искә алуым очраклы түгел. Бүгенге көндә Миңлегөл апага – 82 яшь. Алты ел инде урын өстендә. Өлкән улы Мәсгут тәрбиясендә. Телефоннан шалтыратып, Мәсгут әфәндедән: «Шундый изгелекле эшләгән кешенең хәлен белешүче бармы соң?» – дип сорадым. Аннан: «Юк», – дигән җавап көтмәгән идем...

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

ӘТИ ХАКЫ

Сыната торганнардан түгел

Әтием Ильяс исемле һәм ул бернична ел буена «Камгэсдорстрой» юллар төзү ширкәтендә асфальт түши торган машинада эшли. Эшләренә күп тапкырлар сокланып карап торганым булды. Чиратка тезелгән куәтле КАМАЗлар пары чыгып торган кызу асфальтны бушатып китүгә, ялтырап торган «киң табанлы» катоклар эшкә керешә. Менә шулай, Россиянең гасырлардан килгән «юлсызлык бәласен» бетерүгән күреп, бер сөенеп, бер көенеп куям.

«Көенеп» дигәннән, барыбер бернична айдан соң авыр техникалары белән бастырып, чокыр-чакырга әйләндерәләр бит ул юлларны. «Бер Ильяс Илдус улының техникасы гына көрәшеп җитешә алмый шул...» дигән уйлар да үтә баштан. Минемчә, түземлек, кешеләргә игелек кылу, юк җирдән матурлык булдыру әтиемә дәү әтием Хөҗҗәт Гыймрановтан киләдер. Аны фашистлар, үлде дип, үләксә чокырына ыргыткач, аңына килеп, күп кан югалтуына карамастан, тәнлә белән аягы яралы килеш мәетләр арасыннан үрмәләп чыгып, үзебезнең сугышчылар янына шуышырлык көч тапкан ул. Биш бала үстереп, 89 яшенә кадәр яшәп, бакыйлыкка күчте дәү әти.

Җәйге каникул чорында дүрт яшьлек сеңлем Камилә белән Мамадыш районы Арташ авылына кайтсак та әти безнең белән булырга тырыша. Нәрсәдер эшли башласак, әнием Минзәлия дә: «Әнә әтиегез... ул ни дияр?» – дигән сүзне еш кабатлый. «Нәни дәүләт»ебездә үз урыны бар шул әтиебезнең. Хыялларыбызга юл ачкан чал чәчле әтиемә мин мең-мең рәхмәтле. Ә узган җәйдә Идел буйлап сәфәргә киткәч, төнге икедә башкалабыз Казаннан әйләнеп кайтканчы, Алабуга – Казан юлында мине сагынып көтеп утыручы, тукталышта кизү торучы да ул булды.

Җыйнап әйткәндә, без бер-беребезне күз карашыннан аңлыйбыз. Алга таба искитмәле планнарыбыз бар, сынатырга исәбебез юк безнең.

Нияз ГЫЙМРАНОВ,
10нчы мәктәп укучысы.
Алабуга.

Таланты бәхетле кыз

«Талантлы булу бәхете генә аз, талант та бәхетле булырга тиеш»
Гектор БЕРЛИОЗ.

Татарстан һәм Россия композиторлары берлеге әгъзасы, Нәҗиб Җиһанов исемендәге I Халыкара композиторлар конкурсы, Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты Эльмира Галимова үз талантының бәхет йолдызы күптән кабынган һәм ул аңа юлда очраган киртәләрне узарга ярдәм итә дип саный.

Музыка-моңга чиксез мәхәббәтен Эльмира балачагында ук тоя башлый. Өч яшеннән башлап балалар бакчасында бер генә бәйрәм-кичә дә аның катнашыннан башка узмый. Соңрак кызның бик тә үз көен тудырасы килә башлый һәм ул тугыз яшендә беренче җырын иҗат итә. Шул көннән башлап аның киләчәге, булачак һөнәре билгеләнеп куела. Үзе яшәгән Чаллы шәһәренең 2нче музыка мәктәбен «бишле» билгеләренә генә тәмамлаган кыз, әти-әнисенең каршы булуына да карамастан, Казанга Әүхәдиев исемендәге музыка көллиятенең «музыка теориясе» бүлегенә укырга керә. Кыз, теория белән бергә, Татарстанның танылган композиторлары кул астында көй язып карау серләренә төшенә башлый. Аның беренче педагогы һәм остазы Рәшит Кәлимуллин була. Ул талантлы кызга камера музыкасы язу серләрен, музыканың бик нечкә булуын һәм анда игътибар бирми калдыра торган вак нәрсәләрнең булмавын төшендерә.

Казан музыка училищесын уңышлы тәмамлап, Эльмира Галимова Казан дәүләт консерваториясенең композиция бүлегенә Алмаз Монасыйпов классына укырга керә. Ел ярымнан соң Борис Трубин классында укый башлый һәм консерваторияне кызыл дипломга тәмамлый. Ике остазда белем алу мөмкинлеген дә кыз бәхетле очрак дип саный. Чөнки алар музыка дөньясының серләрен икесе ике яктан, ике биеклектән торып ачалар. Монасыйпов киң масштабта уйларга, зур симфоник жанрлар белән эшләргә өйрәтә. Эльмира Галимованың симфоник оркестр өчен көй язуын күпләр кабул да итми. Башта кечкенә әсәрләр иҗат итеп, композитор булып тәҗрибә тупларга, «җитлегергә» кирәк, диләр. Ә икенче остазы Борис Трубин оркестровканың тирән серләрен ача. Нәкъ менә аның дәресләрендә булачак композитор көй иҗат итәр алдыннан тиешле аһәңне эзләп аптырарга түгел, күңелендә идея туарга, әйтер сүз-фикерең булырга тиеш икәнлеген төшенә. «Үз стилеңне, музыкаль телеңне эзләү шулай ук идеяне эзләүдән башланырга тиеш», – ди Эльмира Галимова, остазы белән килешеп.

Үзенең остазлары турында сөйләгәндә, Эльмира һәрвакыт диярлек әтисен дә искә ала. Нәкъ менә әтисе кызының күңелендә, үзе дә сизмәстән, беренче моңнар яралуга сәбәпче була. Консерваториянең бишенче курсында укыганда, кызга каты авырып киткән әтисе янынннан тугыз ай буе китмәскә туры килә. Әгәр элек кыз көйне фортепиано янында утырып тудырган булса, бу юлы үзенең әче тоемлавына нигезләнеп, заманча технологияләр кулланып иҗат итә. Шулай итеп, Эльмира инструментсыз гына иҗат итәргә өйрәнә. Аның болай музыка уен коралыннан башка гына язылган беренче ораториясе «Изге ядкяр» тиз арада уңай бәя алып, премия белән бүләкләнә.

Эльмира – шактый кыю, тәвәккәл кеше. Музыка училищесында укыганда ук төрле дәрәҗәдәге конкурс-бәйгеләрдә җиңү яулаган иҗатчы үз әсәрләрен тамашачы һәм танылган композиторлар хөкеменә курыкмый чыгара.

Уңышлар белән канатланган талантлы кыз 2010 елда үзенең беренче авторлык концертын тамашачыга тәкъдим итә. 2011 елда Габдулла Кариев исемендәге яшь тамашачы театры сәхнәсендә Рабит Батулла сценариесе буенча куелган «Зәйтүнәкәй» музыкаль драмасының премьерасы була. Аңа көйне Эльмира яза. Аннары кыз «Сөембикә канаты» исемле арт-операсын тамашачы хөкеменә куя. Израиль композиторы Беньямин Юсупов белән «Сәлам-Шалом» дигән тагын бер концерты үзен яратырга өлгергән тамашачыны кабат сөендерә.

– Мине Эльмираның иҗади активлыгы сокландыра, миңа әле аңардан шактый өйрәнәсе бар, – ди Израиль композиторы.

Бу сүзләрдә хаклык юк түгелдер. 2010-2014 еллар эчендә генә дә кыз 20ләп зур жанрдагы әсәрләр иҗат иткән. Аларның иң яхшылары татар профессиональ музыкасының яңа сәхифәләрен ачты. Әйтик, «Сөембикә канаты» дигән арт-операсында катлаулы көй аша кыз тамашачы күңеленә яшәү фәлсәфәсен сала.

«Изге ядкяр» ораториясе (Рабит Батулла либреттосы) Казанның 1000 еллыгына багышланган. Әлеге әсәр 1552 елда канлы вакыйгалар турында. Ул шунда батырларча һәлак булган кыю сугышчылар рухына дога булып яңгырый.

«Зәйтүнәкәй» музыкаль драмасында бөек Тукаебызның кайнар мәхәббәте, аның тирән кичерешләре моң аша бирелә. Әсәрдәге һәрбер геройның үз көен, үз моңын тудыра алган Эльмира.

Яшь композиторның бу әсәрләренә тамашачы, композиторлар, киң җәмәгатьчелек кенә түгел, Татарстан хөкүмәте дә зур бәя бирде. Югарыда санап кителгән тарихи әсәрләре өчен, Эльмира Галимова 2013 елда республиканың Муса Җәлил исемендәге зур бүләгенә лаек булды.

Талантлы композитор ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп кала торганнардан түгел. Бүген аның җырлары республика һәм Россия чикләрен үтеп яңгырый. Татар кызын Алма-Аты, Берлин, Флоренция тамашачысы да алкышлады.

Үзенең иҗаты турында сөйләгәндә, Эльмира еш кына «җан» дигән сүзне куллана. Чөнки ул аның барлык әсәрләренең дә диярлек төп темасын тәшкил итә. Яшь композитор тарихка, татар халкының данлы үткәненә, милли традицияләребезгә еш мөрәҗәгать итә.

Ул үз әсәрләре белән халкыбыз тарихын, моңлы мәгънәле аһәңгә төреп, бар дөньяга тарата. Аның кандидатлык диссертациясенең «Пермь татарларының традицион музыка культурасы» дип аталуы да яшь композиторның фольклорга, халык иҗатына мәхәббәтен күрсәтеп тора. Эльмира Галимова бүгенге көндә Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм һәм сәнгать институтында театр һәм музыка бүлеген җитәкли. Гаиләдә ул – бәхетле хатын һәм әни. Ире җырчы Илнар Гәрәев белән аңлашып-санлашып гомер кичерәләр, бер кыз үстерәләр.

Ә бит Эльмираның тормыш юлы чәчәкләр белән бизәлеп, алкышлар астында гына узмаган. Сынаулары да шактый әзерләгән аңа язмыш. Көтмәгәндә каты авырып китеп, чит ил хастаханәсендә дәваланганда да кыз яшәүгә өметен өзми, иҗат утын сүндерми. Гаиләсенә, дусларына, тамашачысына, халкына кирәк булуны тою авыруны җиңәргә көч табарга ярдәм итә. Эльмираның әнисе ягыннан дәү әнисе танылган шагыйрьләр: Гөлшат Зәйнашева һәм Мөдәррис Әгъләмнең кардәш тиешлесе. Кыз әле моны күптән түгел генә белгән. Хәзер Мөдәррис Әгъләмнең туган авылындагы мәктәпкә аның исемен бирдерү һәм музеен ачу хәстәре белән йөри.

Әле 24 апрель көнне генә филармониянең концертлар залында тамашачы янә Эльмира Галимованың иҗатын барлады. Ә икенче көнне аны Казахстан башкаласында зур бәйге көтә иде. Җыеп кына әйткәндә, моң телендә әйтер сүзләре күп әле Эльмираның. Без аларны йоклаган күңелләрне дә кузгатырлык, бераүне дә битараф калдырмый торган яңа зур әсәрләрендә ишетербез, шәт.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ПОЧТАДАН

Хөрмәт җитми

Мин – авыл баласы. 1939 елда туган кеше буларак, сугыш чорыннан соңгы тормышны бик яхшы хәтерлим. Авылга техника кайта башлавы да, ГАЗ-51 йөк машинасын, ДТ-49 тракторын, «СК» комбайнын бөтен халык белән җыелышып каршы алганыбыз истә.

Сугыштан яраланып кайткан ирләр, буй җиткән малайлар рульгә утырды. Кырда тузанда, челләдә эшләгән комбайнчылар, салкында туңган техниканы кабыза алмыйча җәфаланган, мазутка буялып беткән тракторчылар хәтердә яңарды исә күзләргә яшь тыгыла. Бүген дә шул эшне башкара бу һөнәр ияләре. Тик шундый авыр хезмәт кешесен искә алучы гына юк. Җырчыларны күккә күтәрәләр, алар экраннан төшми, чәчәкләргә күмәләр, ә икмәк үстергән гади хезмәткәрләргә хөрмәт җитми. Комбайнчы, тракторчылар бер мәсьәлә. Шушы җырчыны алкышлаганда, чәчәкләр биргәндә сәхнәдә чыгыш ясаган баянчыларның читтә калуына да күңел риза түгел. Монда 16-17 килолы баянны күтәреп тору белән генә түгел, әле моңа Ходай биргән сәләт тә кирәк бит. Нигәдер, гомер буе җырчы күләгәсендә кала кебек алар.

Иркәм ХӘЙРЕТДИНОВ,
Ульяновск.

«Яңа Гасыр» телеканалы алып баручыларга кастинг игълан итә!

ТНВ ТАТАРСТАН

«Яңа Гасыр» телеканалы иртәнге «Манзара» тапшыруын алып баручыларга кастинг игълан итә.

– Без үзебезнең тамашачылар арасында кастинг үткәрергә булдык. «Манзара» тапшыруында алып баручылар үзгәрү иртәнге тапшырулар программасы яңаруга бәйле, – дип аңлатты телеканалның иртәнге тапшырулар иҗат берләшмәсе җитәкчесе Леонард Дәүләтшин.

Кастингны оештыручылар катнашучыларга берничә мәҗбүри таләп куйган. 25-40 яшьләрдәге кандидатлар югары белемле булырга һәм чиста әдәби татар телендә сөйләшә белергә тиеш. Шулай ук катнашучының моңарчы зур аудиторияләр белән эшләве хуплана, тышкы кыяфәте дә мөһим роль уйный.

Катнашу турында резюме хатын pr_tnv@mail.ru электрон адресына «Кастинг» тамгасы белән җибәрү сорала. Резюмеда, һичшиксез, катнашучының тулы буе кергән фотосурәте булуы шарт, аның йөзе якыннан яктыртылган булырга тиеш.

«Бөтен чәчәкләрне җыеп, сезгә бирәсе килә»

Шушы көннәрдә «Әкият» Татар дәүләт курчак театры коллективы Сахалиннан гастрольләрдән кайтты. 10 мең чакрымнан артык ераклыктагы утрауда урнашкан әлеге шәһәр белән ике арада гастрольләр алмашу уе каян килгән соң? Бу хакта театр директоры Роза Җаббаровадан белештек.

МӘДӘНИЯТ

– Сахалин губернаторы Олег Кожемяко Татарстанга Президент Рөстәм Миңнеханов белән ике арада хезмәттәшлек турында килешү төзергә килгән иде. Аның хатыны безнең театрны килеп карады һәм ошатып китте. Ул ике арада гастрольләр алмашуга үзенең теләген җиткерде. Соңыннан Сахалин курчак театры директоры белән телефон аша сөйләштек. Алар да әлеге алмаш гастрольләрне хуплады. Башта без Сахалин курчак театрын үзебездә кабул иттек, аннары аларга китеп бардык. Самолеттан төшүгә, җитәкчеләр, татар милли-мәдәни үзәге вәкилләре кабул итте. Без анда алып бару өчен Адел Хәеровның «Три дочери» әкиятен сайладык.

– Сезнең репертуарда кызыклы спектакльләр шактый. Ни өчен әлеге спектакльгә тукталдыгыз?

– Русча булса да, татар җыр-биюләре белән куелган ул. Курчаклар гына түгел, анда артистлар да милли киемнәрдән. Балалар өчен «Идет коза рогатая» спектаклен күрсәттек. Артистлар аларны сигез тапкыр уйнады. Алты көндә спектакльләребезне 2000 тамашачы карады. Бигрәк тә залда утырган милләттәшләребезне күреп сөендек. Өлкән яшьтәгеләрнең күзләрендә яшь иде. Татар милли-мәдәни җәмгыяте җитәкчесе Зәкия Вәлитова язган хатны сезгә дә тәкъдим итәсе килә. «Хөрмәтле милләттәшләрем, татар мәдәниятен, гореф-гадәтләрен безгә спектакль аша күрсәткәнегез өчен зур рәхмәт. Җир йөзендәге бөтен чәчәкләрне җыеп, сезгә бирәсе килә. Сезнең белән очрашкан вакытлар, бер мизгел булып, истәлеккә татарлар тарихына кереп калды. Күздән яшьләр тама, сезнең белән аерылышу бик ямансу...»

– Сахалинда электән шактый милләттәшләребез яшәгән. Бүген аларның хәле ничек?

– Әйе, заманында безнең яклардагы халыкны шунда каторгага җибәргәннәр бит. Ничек итеп анда җәяү барып җитә алганнардыр алар. Бүген Сахалинда шуларның оныклары, нәселләре гомер кичерә. Үзебезнең коллективтан Гүзәл Маннапова шунда туганнарын табып кайтты. Күрешергә дип 800 чакрым ераклыктан килеп җиттеләр. Безне кунак иткән Зәкия Вәлитова тумышы белән Чүпрәле районыннан. 19 яшендә төзелешкә килеп эшли башлаган. Бүгенге көндә ул анда абруйлы кешеләрнең берсе. Татар милләте өчен күп эшли, балалар йортларына ярдәм итә. Аларны диңгезгә алып бара. Балалары да дәрәҗәле урыннарда эшли. Зәкия ханым милләттәшләрне даими очраштырып тора. Милли ризыклар пешерәләр, татар җырларын онытмыйлар. Яшьләр белемле. Анда да, бездәге кебек, заводлар юкка чыккан. Халык балыкчылык белән шөгыльләнә.

– Шәһәрнең истәлекле урыннарын карарга өлгердегезме? Нинди тәэсирләр белән кайттыгыз?

– Безнең бөтен артистлар да, бөтенләй башка планетада булдык, диештеләр. Шәһәрләре бик чиста. 193 мең кеше яши. Күбесе – рус, татар, украин халкы. Театрлары икәү генә. Берсе – курчак, икенчесе – драма театры. Туган якны өйрәнү һәм Чехов музейлары бик кызыклы. Милләттәшләребезнең руслаша баруы гына аянычрак.

Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе паркында агач утырту күркәм гадәткә әйләнде.

Истәлеккә

Филармония паркында моңа кадәр Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров һәм Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Әлфия Авзалова, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов, Татарстанның халык артисты Флюра Сөләйманова исеменнән агачлар утыртылган иде. Быел исә дирижер, СССРның халык артисты Натан Рахлин белән композитор, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты Җәүдәт Фәйзи истәлегенә утыртылды.

Чарада филармония җитәкчеләре, сәхнә ветераннары, Урман хуҗалыгы министрлыгы вәкилләре катнашты. Натан Рахлин турындагы истәлекләре белән танылган виолончель остасы Лариса Маслова уртаклашты.

– Мин хезмәт юлымны Натан Рахлин җитәкләгән оркестрда башлап җибәрдем. Гаҗәеп дәрәҗәдә югары культурага ия, зыялы, күпкырлы шәхес иде ул. Ул аталарча кайгыртучан да булды. Шундый шәхесләр истәлегенә агач утырту – бик изге эш, – дип сөйләде Лариса ханым.

Җәүдәт Фәйзине якыннан белгән Флюра Сөләймановaның да композитор турында әйтер сүзләре бар.

– Бала чакта «Карак песи» җырын җырлап йөри идем. Аның көен Җәүдәт абый язганын ул чакта каян белим. Мин Ульяновск филармониясендә эшләгәндә, ул миңа «Гөлшаһидә» җырын язып бирде. Бу җыр бик популяр булып китте. Аның башка җырларын да җырларга туры килде. Җәүдәт абыйны мин кешелекле, ярдәмчел шәхес буларак та искә алам, – ди җырчы.

Гүзәл Әсәл – кабат сәхнәдә

Без үсмер елларда зәңгәр экраннардан караган «Гүзәлем Әсәл» (Чыңгыз Айтматов) спектаклен Әтнә дәүләт драма театры кабат сәхнәгә менгерде. Аны Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин сәхнәләштерде.

Заманында Камал театры сәхнәсендә Әсәл ролендә – Наилә Гәрәева, Ильясны Ренат Таҗетдинов уйнаган иде. Шулай ук Шәүкәт Биктимеров, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Ирек Баһманов кебек күренекле артистларның уйнавы да истә әле. Билгеле, яңа гына профессиональ баскычка күтәрелеп килгән театр коллективы белән аларның уенын чагыштыру дөрес булмас иде.

Шофер егет Ильяс Әсәлгә бер күрүдә гашыйк була һәм алар гаилә корып җибәрәләр. Әмма аларның бер-берсен яратулары да гаиләне саклап калмый. Арада хыянәт булганда, мәхәббәт уты озак дөрли алмый шул. Иренең хыянәтен Әсәл кичерә алмый. Ул үзенең язмышын, юлында беренче очрап, аңа карата игътибарлы булган Байтимер белән бәйли. Тыйнак, чибәр, горур Әсәл ролен Гүзәл Гафарова башкарды. Аның образы аша бүген кайбер кызларда әнә шул сыйфатлар җитеп бетмәвен күрәсең. Фаяз Хәсәенов үз роле (Ильяс) белән тамашачыда нәфрәт уятса да, уйнавы белән сөендерә. Югалтканнан соң гына ул үзенең сөюен аңлый. Байтимерне гәүдәләндергән Айдар Вәлиев үзенең олы җанлы булуына тамашачыны да ышандырды. Зөһрә Мөхәммәтшинаны үз бәхете өчен көрәшә белгән хатын-кыз ролендә күрдек. Аның Ильяс өчен өзгәләнүләре беркемне дә битараф калдырмый. Ләкин ике яклы мәхәббәт нигезендә корылмаган гаилә тотрыклы булып чыкмый. Зөһрә моннан берничә ел элек Илдар Хәйруллин курсында белем алган иде. Әлеге роле өчен ул быел «Тантана» премиясенә дә лаек булды. Татарстанның атказанган артисты Марат Хәбибуллин теләсә кайсы рольдә дә үзен оста башкаручы буларак күрсәтә.

Заманында Әсәл булып уйнаган Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Наилә Гәрәева коллективның уенын ошатты.

– Без, уйнаганда, Чыңгыз Айтматов әсәренең күтәренке рухта икәнен тойдык. Бездә аны Үзбәкстаннан килгән режиссер куйган иде. Ул чакта киемнәрдә миллилек тә бар иде. Замана да башка иде бит. Шушы спектакльдә уйнап, Тукай премиясе алдык. Әлеге спектакльне караганда да үзебез уйнаган чаклар күз алдына килде. Илдар Хәйруллин әсәрне заманча, гади итеп сәхнәләштергән. Мин, гомумән, Әтнә театры артистларын яратам. Спектакльне Марат Әхмәтшин язган музыка бик күтәрә. Яшьләр дә әйбәт уйнады, – диде ул.

Сәхифәне Люция ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде.

«Беркайчан да бернәрсәдән дә курыкмаска»

Илгиз Мәҗитов – Казан егете. Бала чагы башкаланың Кече Кызыл урамында үтә. Барлык малайлар кебек, тубын да тибә, хоккей да уйный, сәпиттә дә чаба. Үсмерлек чоры 70нче елларга туры килә. «Самоцветы», «Ариэль», «Песняры» ансамбльләренең бик популяр чагы бу. Ул елларда барлык яшүсмер егетләр, «Битлз» музыкантларына охшарга тырышып, озын чәч үстереп, гитара чиртә. Башкалардан аермалы буларак, Илгиз Мәҗитов өчен бу вакытлы мавыгу гына булмый. Музыкага мәхәббәт аның тормышында аерым урын алып тора. Алар өч дус – Женя Нефедов, Дима Макаров һәм Илгиз вокаль ансамбль оештырырга карар кыла. Гитара буенча беренче дәресләр Менжинск клубында уза.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

– Үземә дип атап гитара алган көнне бүгенгедәй хәтерлим. Гитара ул вакытта бик дефицит. Укытучыбыз белән Бауман урамындагы Үзәк Банк каршына урнашкан «Культтовары» кибетенә киттек. Миңа Питерда эшләнгән гитара ошады. Бәясе – 17 сум 50 тиен. Бу 1971 ел. Нәкъ менә шушы көннән соң музыка белән җитди шөгыльләнә башладым һәм бүгенгәчә бу минем яшәешемнең аерылгысыз өлеше, – дип истәлекләре белән уртаклаша Илгиз Мәҗитов.

Ансамбль белән иң беренче тапкыр алар Юрий Антоновның «О добрых молодцах и красных девицах» җырын башкаралар. Аннан соң ансамбль үз эшен мәктәптә Михаил Милентьев җитәкчелегендә дәвам итә. Колонкалар, микрофоннар алалар, тавыш көчәйткечләрне егетләр радиотехника дәресләрендә үзләре ясый. Бу өчлеккә барабан һәм торба кушыла. Янып, дулкынланып, концертларга әзерләнеп йөргән мәктәп елларын Илгиз Мәҗитов әлегәчә күңелендә саклый. Хәер, аннан соңгы тормышында да барлык вакыйгалар да гел шушы ансамбль тирәсендә кайный кебек.

Егетләр 1975 елның июль аенда сәнгать җитәкчеләре Михаил Милентьев белән Тольятти шәһәрендә Грушин фестивалендә чыгыш ясарга тиеш булалар. Илгиз Мәҗитовка исә язгы чакырыда армиягә китәсе. Аллаһ рәхмәтеннән ташламый, институтта кичке факультетта уку сәбәпле, аны көзгә калдыралар. Көз көне дә чакыру белән хәрби комиссариатка килергә тиешле көндә аларның концерты билгеләнгән була. Шуңа ул военкоматка да икенче көнне генә бара. Армия сафларында хезмәт итү егет өчен зур мәктәп була. Аннан кайтканнан соң Мәскәү энергетика институтының Казан филиалына укырга керә. Институтта да Илгиз Мәҗитов яңа ансамбль оештыра. Ансамбль 40 елдан соң да үзенең тыңлаучыларына һәм җырчыларына гел шатлык бүләк итеп тора.

Институтны ул «биш»кә генә тәмамлый. Аның лекция язган дәфтәрләре курста иң чистасы була. Бөтен формулаларны, мөһим кагыйдәләрне аерым төс белән язу гадәте әлегәчә дәвам итә. Эш өстәлендә дә, көндәлегендәге язмаларында да пөхтәлек, чисталык. Хезмәт юлын ул Казанның точмаш төзү заводының дүртенче цехында энергетик булып башлап җибәрә. Яшь егеткә бик җаваплы өлкә әләгә, ул станокларның өзлексез эшләвен тәэмин итәргә тиеш була. Төп проблемаларның берсе – двигательләрнең кызып эштән чыгуы. Моны төзекләндерү күп вакыт таләп итә, ярый ла тиз генә кирәкле әйберләре булса. Илгиз Мәҗитов яңа технология уйлап таба, двигатель кыза башласа, үзеннән-үзе аерып куя. Соңрак башка заводлар да аның тәкъдиме белән яңа төр технология кулланып эшли башлыйлар. Бу – яшь энергетикның иң беренче җиңүе.

Үзенең уңышлары өчен Илгиз Мәҗитов остазларына рәхмәтле.

– Производствода эшләү – бик зур мәктәп ул. Яшь белгеч буларак мин кешеләр белән аралашырга, үзара мөнәсәбәтләр урнаштырырга, эш дәверендә үзем өчен генә түгел, коллектив өчен дә җаваплылык тоярга өйрәндем. Остазларым кайбер сыйфатларны холкыма өлге итеп салдылар. Цех җитәкчем Илдус Сәлимуллин: «Беркайчан да бернәрсәдән дә куркырга кирәкми. Җиңеңне сызган да эшлә», – ди торган иде. Бу минем гомерлек девизым булды, – ди ул.

Энергетика өлкәсендә төрле баскычтагы җитәкче вазифаларын башкара Илгиз Мәҗитов. Кайда гына эшләмәсен, аны һәрчак мактап, сагынып искә алалар. 2009 елдан ул «Татэнергосбыт» җәмгыятендә электр энергиясен куллану идарәсен җитәкли. Бик тә җаваплы, тиз арада күп төрле стратегик сорауларга җавап бирүне сорый торган тармак.

«Талант һәм эшкә мәхәббәт арасында чикләр юк», – дип әйтә торган булган Людвиг ван Бетховен. Илгиз Мәҗитов белән янәшә эшләгән һәркем аның күпкырлы талантына, эшкә мөнәсәбәтенә, тормышны яратуына хәйран кала. Шушы көннәрдә аңа 60 яшь тула! Коллективта уза торган бер генә бәйрәм дә аның җырларыннан һәм гитарасыннан башка үтми. Аңардагы көч-дәрман бөтен кешегә җитә. Илгиз Мидхәт улы белән аралашканнан соң тормышны, кешеләрне ныграк ярата башлыйсың. Юкка гына энергетика өлкәсендә эшләми, чын мәгънәсендә кешеләргә уңай энергетика тарата ул.

Космонавтлар урынына – менеджерлар

Узган гасырның 60-70нче елларында укучыларга: «Үскәч кем булырга телисең?» – диген сорау бирсәң, алар космонавт, танкист, инженер, генерал, очучы, диңгезче, дип җавап бирерләр иде. Аңлашыла да, патриотик тәрбия йогынтысында үскән балалар яшьтән үк хәрби киемнәр киеп, марш басып йөрергә ярата- лар, ул вакытларда мәктәпләрдә дә пионер дружиналары бар, «Аҗаган» хәрби уеннары ел саен үткәрелә иде.

ПОЧТАДАН

Хәзерге балалар башкачарак уйлый, фән-техника йогынтысы да сизелеп тора, кеше саен телефон, компьютер. Кечкенә балага кадәр кесә телефоны сорап йөдәтә. Мәктәп укучылары хәзер китап укырга яратмый, аңа интернетта утыру рәхәтрәк.

Бүгенге чыгарылыш укучылары нәрсә белән кызыксына һәм алар нинди һөнәр вәкилләре булырга җыеналар соң? Социологик тикшеренү нәтиҗәләре буенча, 2017 елда Россиядә иң популяр һөнәрләр исемлегендә икътисадчы, менеджер, юрист, программист, маркетолог һәм пиар белгечлеге тора икән.

Менеджер – инглиз теленнән тәрҗемә иткәндә башлык, түрә, җитәкче дигәнне аңлата. Бүген бу һөнәр, үзенең популярлыгы белән, иң югары дәрәҗәдә. Әлеге һөнәр иясе һәр җирдә кирәк. Урта дәрәҗәдәге менеджер аена якынча 1500-2000 доллар хезмәт хакы ала. Аңа уңышлы башкарган эшләре өчен акча өстәргә мөмкиннәр. Менеджмент факультетларына укырга керү җиңел түгел. Бер урынга 25ләп кеше дәгъва белдерә.

Программист – XXI гасырның югары технологияләре белән бәйләнгән белгечлек. IT өлкәсендәге белгечләргә аеруча ихтыяҗ зур. Тәҗрибәле программистлар Россиядә иң югары хезмәт хакы алучылар булып хисаплана. Шунысын да истән чыгармаска кирәк, программалар инглиз телендә языла, шуңа күрә ул телне камил дәрәҗәдә белү сорала. Бу белгечләр дә һәр җирдә кирәк, берсе дә эшсез утырмый.

Ничек кенә булмасын, диплом ул катыргы гына, һөнәреңбуенча югары дәрәҗәләргә күтәрелер өчен, үз өстеңдә даими эшләргә, белемеңне арттырырга, яңалыклардан артта калмаска, үз эшеңнең чын остасы булырга кирәк. Бары шул чакта гына зур хезмәт хакы алып эшләргә, җәмгыятьтә хөрмәткә лаек кеше булырга мөмкин.

Нияз БИШБАЛТА,
Казан.

Файдалы чара

Безнең 5нче лицейда «Мин татарча сөйләшәм» акциясе кысаларында үткәрелгән кичә җыр-бию, милли традицияләребез, халык авыз иҗаты һәм инглиз теле белән бергә үрелеп барды. «Тукай атналыгы»нда укучылар арасында төрле бәйгеләр игълан иткән идек: балалар иншалар яздылар, рәсемнәр ясадылар. Атналык та бик җанлы узды.

Шунысы сөендерә, рус һәм башка милләттән булган укучылар да без үткәргән чараларда бик кызыксынып катнашалар. Төбәкара дистанцион олимпиадаларда, «Зирәк тиен» олимпиадасында, төрле фәнни-тикшеренү конференцияләрендә уңышлары дипломнар белән бәяләнә. «Бу чара вакытлы акция булып кына түгел, ел буена сузылган дәвамлы эш булса, файдасы күп булыр иде», – диләр укытучылар да, укучылар үзләре дә.

Гөлназ ТАҺИРОВА,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
Казан.

Симәнәң сәламәтме?

Хәзерге вакытта Татарстан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре алдында торган төп бурыч – язгы кыр эшләрен лаеклы башкарып чыгу. Шуңа күрә бүген һәр агроном хуҗалыктагы орлыкларның ни белән авыруларын белеп торырга тиеш, дип саный Россия авыл хуҗалыгы үзәгенең Татарстан буенча филиалы җитәкчесе урынбасары Галина Полях.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Аның сүзләренчә, орлыклар күпчелек очракта фузариоз, альтернариоз, гельминтоспориоз, септориоз, күгәрек, бактериоз кебек авырулар белән авырый. Мәгълүм булганча, 60 проценттан артык авыру орлыктан күчә. Белгечләр әйтүенчә, яхшы уңыш җыеп алуга комачаулык итә торган әлеге авыруларны ачыклар өчен, орлыкларга фитопатологик анализ ясарга кирәк. Фитоанализ ни бирә соң? Аның нәтиҗәләре буенча, белгечләр орлык агулагычларын сайлап ала. Алар тамырның черүен 35 процентка кадәр саклап калырга һәм уңдырышлылыкны гектарына 5 центнерга кадәр арттырырга ярдәм итә. Авырулар арасында иң куркынычлары – фузариоз һәм гельминтоспориоз, чөнки нәкъ менә алар тамырның черүенә китерә, ди белгечләр.

– Орлыклар фузариоз һәм гельминтоспориоз инфекциясе белән ун процентка кадәр зарарланган очракта, аларны биофунгицидлар белән эшкәртү дә җитә. Зарарлану 10-15 процентка кадәр тәшкил итсә, бер һәм ике компонентлы, ә 15-30 процентта өч компонентлы химик препаратлар файдаланырга кирәк. Ә инде орлык 30 проценттан да артык зарарланган булса, ул чәчү өчен яраксыз була, – дип аңлатты безгә Галина Полях.

Бүгенгә Россия авыл хуҗалыгы үзәгенең Татарстан буенча филиалы белгечләре кырларга чәчелергә тиешле 213,7 мең тонна материал тикшергән. Язгы бодай орлыгы шуларның 79,6 мең тоннасын тәшкил иткән. Шушы тикшерелгән материалларның 21,6 процентының зарарланган булуы ачыкланган.

Белгечләр әйтүенчә, бодай һәм арпа фузариоз-гельминтоспориоз инфекциясе белән аз дәрәҗәдә зарарланган. Ә менә орлыкларның күгәрүе соңгы елларда ешрак күзәтелә башлаган.

Моның сәбәбе – урып-җыйган һәм саклаган вакытта кагыйдәләрнең бозылуы һәм ашлыкның җәрәхәтләнүе. Агротехник кагыйдәләр буенча, чәчү ашлыгын ваклау бер проценттан да артып китмәскә тиеш. Әмма күпчелек очракта ул 2-10 процентны тәшкил итә. Җәрәхәтләр – инфекция барлыкка килсен өчен менә дигән сәбәп. Бу очракта Ризоплан, Ж, Псевдобактерин–2, Ж һәм башка биофунгицидлардан файдаланырга кирәк. Әлеге препаратлардагы тере бактерияләр микроҗәрәхәтләрне дәвалый һәм авырулар таралуга комачаулык итә, – ди ул.

Россия авыл хуҗалыгы үзәгенең Татарстан буенча филиалы белгечләре төрле фунгицидлар һәм микробиоашламаларның нәтиҗәлелеген ачыклар өчен шулай ук актив эш алып бара. Биофунгицидларны микробиоашламалар белән бергә куллану орлыкның шытучанлыгын арттыра, инфекцияләр белән зарарлануын киметә, үрентеләрнең үсешенә булыша. Шуңа күрә аграрий белгечләре Россия авыл хуҗалыгы үзәгенең Татарстан буенча филиалының агулагычлар сайлау буенча киңәшләренә елдан-ел ныграк колак сала. Мондый хуҗалыклар хәтта корылык елларында да оттырмый. Мәсәлән, шундый районнар исемлегенә Баулы һәм Биектау аграрийларын мисал итеп китерергә мөмкин.

БЕЛЕП ТОР!

Татарстанда 25 апрельдән 15 майга кадәр янгыннарга каршы махсус режим кертелде. Шушы чара кысаларында Яшел Үзән районы урманчылыгында янгын сүндерү һәм гадәттән тыш хәл зыянын бетерү буенча өйрәнүләр узды.

Учак яксаң, сүндерергә онытма

Коры үләнгә капкан ут, тора-бара, урманга күчеңә. Янгын «Мечта» сәламәтләндерү лагерен һәм Нарат бистәсендәге сигез өйне ялмап ала. Урман хуҗалыгы министрлыгының янгын сакчылыгы утны үзе генә җиңәрлек түгел. Федераль янгын сүндерү хезмәтенең 8нче отряды һәм хәтта янгын сүндерүгә махсуслаштырылган Ми-8 вертолеты ярдәмгә килде. Уртак тырышлык белән янгын сүндерелде, кешеләр коткарылды. Янгын колачын ачыклау өчен пилотсыз очкыч аппараты да кулланылды.

Шөкер, бу өйрәнүләр генә. «Мечта» лагере да, Нарат бистәсендәге чын өйләр дә янмады, ә өйрәнү максатында муляж, ягъни алдан ясалган макетлар файдаланылды.

– Бүген ярый урамда яңгыр ява. Әмма язын җир бик тиз кибә. Гадәттән тыш коры көннәрдә бакчаларда, болыннарда һәм кырларда корыган үләннәрне ягу катгый рәвештә тыела. Коры көннәр башланганда, урманда учак кабызырга ярамый. Сүнмәгән шырпыны яки тәмәке төпчеген коры үләннәргә, агачлыкка ташлыйсы түгел. Саксызлык урманнарга һәм аңа якын урнашкан өйләргә, корылмаларга ут кабуга китерә, – дип искәртте Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге җитәкчесе Нияз Тазмиев.

Урманнарда янгыннарга каршы кагыйдәләрне бозган очракта, физик затларга – 2 меңнән 5 мең сумга, ә җитәкчеләргә 7 мең сумнан 50 мең сумга кадәр штраф салына. Юридик затларны исә 50 мең сумнан 1 миллион сумга кадәр штраф көтә.

Татарстан урманнарында, болыннарда һәм кырларда янгыннар күрсәгез, кичекмәстән, Урман хуҗалыгы министрлыгына **8-800-100-94-00** номеры аша хәбәр итү сорала.

ХЕЗМӘТ ИМИНЛЕГЕ

Эш урыны «сугыш мәйданы» түгел

Бөтен дөньяда 28 апрель – Хезмәт иминлеген саклау көне буларак билгеләп үтелә.

– Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республикада хезмәт иминлеген саклау мәсьәләсенә бик катгый. Әлбәттә инде, иртән эшкә чыгып киткән кеше кич исән-имин өенә кайтып кереrгә тиеш. Хезмәт иминлеген саклау максатларында күп чаралар күрелә. Ләкин әлегә Россиядә эш урынында имгәнү алулар, чит илләр белән чагыштырганда, дүрт мәртәбәгә күбрәк, – диде республиканың хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Саннарга күз салсак, 2010 елда республикада эш урынында 100 кеше фаҗигале төстә үлгән, 1020 кеше төрле авырлыкта имгәнүләргә дучар булган.

Узган ел җитештерү тармагында – 35, ә быелның беренче кварталында җиде кеше үлгән.

– Эш урынында фаҗигале очраклар саны елдан-ел кими. Татарстан Президенты бурыч итеп куйганча, максатыбыз – җитештерү тармагында имгәнеп үлү санын «ноль» күрсәткеченә төшерү, – диде Эльмира Зарипова.

Министр республика муниципаль берәмлекләрендәге хезмәт иминлеген саклау мәсьәләләре белән шөгыльләнүче Координация советлары эшчәнлегенә нык әһәмият бирде.

– Дәүләт хезмәт инспекторлары быел 466 предприятиедә һәм оешмада хезмәт турындагы законнарның үтәлешен тикшерде. Хезмәт иминлеге тәэмин ителмәгән өчен, 857 җитәкче административ штрафка тартылды, ә өч кешегә җинаять эше кузгатылды. Алар ике һәм өч ел срокка ирекләреннән мәхрүм ителделәр. Коллективта кеше саны 50дән артса, анда хезмәт иминлеге өчен җаваплы штат булырга тиеш, – дип кисәтте Эльмира Зарипова.

Татарстанда хезмәт шартларын һәм хезмәт иминлеген яхшырту буенча 2020 елга кадәрге чорга исәпләнелгән программа гамәлгә ашырыла. Узган ел эре предприятиеләрдән 45 мең җитәкче һәм белгеч, кече һәм урта предприятиеләрдән, шулай ук мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният тармакларыннан 4404 хезмәткәр хезмәт иминлеген саклау буенча махсус курслар узган. Укыту-өйрәтү эшләре дәвам итә.

– Эш урынында иминлек мәсьәләсендә шәхси җаваплылык та зарур. Киң балаклы ыштан, төймәләре каптырылмаган халат киеп, станокта эшләргә ярамый инде, әлбәттә. Корыган агачларны унбиш ел кисү белән шөгыльләнгән тәҗрибәле эшчене корыган агач ботагы төшеп үтерде. Агач кискәндә, ботаклар астында басып торырга кирәкми бит инде, – дип уфтанып та алды министр Эльмира Зарипова.

Дамир БӘДРИЕВ.

«Мәхәббәтле тамаша»

Бүген кояш беренче тапкыр җиргә назлы итеп карады. Җил дә тынып калган. Авыл өстендә бары тик туган якларын сагынып кайткан кара каргалар тавышы гына ишетелә.

Яз килә, яз гына түгел, язның беренче илчеләре белән бергә Татар Ялтаны авылына концерт программасы белән яшь артистлар да килә. Авыл халкы күптән инде аларның килүен түземсезлек белән көтә. Өлгерләре алдан ук билетлар алган инде. Кич белән безнең Мәдәният йортына халык агыла башлады. Сәхнә матур итеп бизәлгән. Түрдә ике яшьнең зур фотосурәтләре куелган. «РӘФИЛ» һәм «ЭЛЬМИРА» дигән язулар язылган. Ә уртада «Мәхәббәтле тамаша» – бусы инде бүгенге концерт программасының исеме.

Халык тамаша башлануны түземсезлек белән көтә.Берничә тапкыр кул да чабып алдылар инде, тизрәк күрәселәр килә бит яшьләрне.

Дәртле көй астында сәхнәбез түренә «Татар моңы» һәм Рәшит Ваһапов фестивале лауреатлары Рәфил Җәләлиев һәм Эльмира Гыйльфанова килеп чыкты. Алар үзләренең иң матур җырлары белән бүгенге тамашаны башлап җибәрделәр. Эльмираның моңлы, сихри тавышы, үз-үзен тотышы, ягымлы сөйләме барлык тамашачыны да таң калдырды. Халкыбыз җырлары да, замана композиторларының җырлары да зур осталык белән башкарылды.

Рәфил Җәләлиевнең дәртле җырлары әбиләрне дә елмаерга, утырган җирдән генә булса да «биергә» мәҗбүр итте. Аның матур итеп, тәмле итеп сөйләве, төрле темаларга багышлап башкарган көчле җырлары күңелләрдә дә, җырлатты да, елатты да.

Тамашада күпсанлы интригалар да булды. Димләүче Ириналың һәм биюче Диләрәнең чыгышлары да тамашаны күңеленә үтеп керде. Алар мәхәббәтле тамашаны чын тамашага әйләндерүгә ярдәм иттеләр.

Концерт буена авылыбыз сәхнәсен яктыртып торучы баянчы егет – авылдашыбыз, «Татар моңы» конкурсы лауреаты, Казан дәүләт мәдәният-сәнгать институтында концертмейстер булып эшләүче Әлфис Галиуллин булды. Әлфиснең «Туган авылым – Ялтаным» дигән җыры сәхнәдә тәүге тапкыр яңгырады. «Урман» дигән җырның да премьерасы нәкъ менә туган авылының клуб сәхнәсендә тәкъдим ителде. Баянда төрле көйләргә тезмә башкарганда, халык Әлфисне аягүрә басып тыңлады. Чөнки башкача аңа соклануны, аны яратуны, аны сагынуны белдереп булмый иде. Афәрин, авылдашыбыз!

Концерт искиткеч булды. Мондый тамашаның әле безнең клуб сәхнәсендә беркайчан да күрсәтелгәне булмады. Яшьләрнең энергиясе ташып тора, аларны тыңлыйсы да тыңлыйсы гына килеп тора. Татар җырының, татар моңының саклануы шушы Рәфил, Эльмира, Әлфисләр кулында. Тере тавышка җырлап, татар җырының бөтен нечкәлекләрен биреп, һәр тамашачы күңеленә үтеп керә алдылар алар. Һәркайсы үзләренең театр артисты була алырлыкларын да расладылар. Ә аларның концерт киемнәре тамашага олы ямь өстәде. Чиста итеп яздырылган музыка да, чиста яңгыраш та тамашачыга бу яшьләрнең (төркемнең) профессиональ югарылыкта икәнлеген күрсәтте.

Концерт тәмам. Ә тамаша залыннан халыкның китәсе килми. Без авылдашларына шундый көчле концерт белән кайтып, безне рәхәтләндереп ял иттергәне өчен, Әлфис Галиуллинга чиксез рәхмәтебезне җиткерәбез. Әлфиснең шундый якын, туры дуслары булуына шатланабыз. Яшь, талантлы, сәләтле, булдыклы, моңлы, тырыш яшьләребезгә бары бер генә теләк – сәламәтлек, изге юллар, иҗади уңышлар.

Гүзәл ГАЛИЕВА,
Лидия МАССАРОВА.
Чистай районы, Татар Ялтаны авылы мәдәният йорты хезмәткәрләре.

Яшисе килеп яшәгәндә!

«Наркотикларсыз клуб тормышы» проекты идеясе ун еллап элек туа. Республика хокук саклау органнары өчен 2007 ел җиңелләрдән килми: Татарстанда наркотик бәйлелеккә эләккән халык санының үсеш темплары 7%тан артып китә. Шулай да тиздән әлеге күрсәткеч кимү ягына авыша, ә проект күңелсез вазгыятьне туктату коралына әверелә.

БАЛЫКЧЫ БАЛЫК БУЛГАН УРЫНГА КИЛӘ

Проектны ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы оештыра, ә аны гамәлгә ашыруга республиканың берьюлы берничә ведомстводы кушыла: Наркотик матдәләр әйләнешенә контрольлек итү буенча РФ федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе, ТР буенча ЭЭМ һәм Республика наркодиспансеры.

– Безнең өчен төнге клубларда һәм аларга якын территорияләрдә наркотиклар куллануны булдырмаслык шартлар тудыру мөһим иде, – дип сөйли ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының өстәмә белем бирү һәм социаль программалар бүлеге җитәкчесе Наталья Пивоварова. – Алай гына да түгел! Күпчелек кешеләрнең аңында, төнге клубларга бары тик наркоманнар гына йөри һәм анда наркотиклар саталар, дигән стереотип яшәп килә иде. Менә шуны җимерергә кирәк булды. Клубларның үзләрендәге администрация ярдәменнән башка моны эшләү гаять авырга туры килер иде.

НАРКОТИКЛАРДАН АЗАТ ТЕРРИТОРИЯ

Проект эшли башлаганнан бирле анда республиканың 33 төнге клубы катнашкан.

– Идеябезнең, шул исәптән иң эре клублар тарафыннан хуплануына без бик шат булдык, – ди ТР буенча ЭЭМның Наркоконтроль идарәсе башлыгы урынбасары Кирилл Жданов. – Проектта катнашучыларның барысы да, без уртак эш эшлибез, дигән фикергә килде. Бу узара аңлашып эшләргә мөмкинлек тудырды.

Төнге клубларда эшләүче персоналны укыту мөһим аспект булып тора. 30дан артык семинар үткәрелгән. Наркотикларның яңа төрләре турындагы мәгълүмат белән коралланган 270 кеше «фейс-контроль»гә баскан һәм клубтагы «куркыныч зоналарга» күзәтчелек итә башлаган.

2016 елда хокук саклау органнары хезмәткәрләре республика клубларында 61 операция оештырган. Наркотик куллану-кулланмау җәһәтеннән 360ка якын кешегә тикшерү үткәрелгән. Нәтиҗәдә 13 кешегә карата булган шик расланган.

КЛУБ ТОРМЫШЫ ЭВОЛЮЦИЯСЕ

Листовкалар тарату, роликлар әйләндерү, клубларда төрледә-төрле интерактивлар үткәрү – проектның пиар-арсеналын әнә шулар тәшкил итә. «Яңарырга вакыт җитте!» – дип саныйлар анда катнашучылар.

Наркоконтроль идарәсе һәм ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының уртак киңәшмәсенә клуб директорлары да чакырылар. Соңгылары кайсы юнәлештә эшләргә кирәклеген төгәл аңлыйлар.

Әйтик, «Арена» клубы директоры Тәлгать Закиров сүзләренә караганда, бүген наркотикларга каршы сәясәт, нигездә, куркытуга корылган. Әмма яшьләрнең холкы шундый инде: мондый куркытуларга әллә ни исләре китми. Ләкин шуның белән берррәттән, бүгенге яшьләрне кичәгеләреннән үз язмышларына зуррак җаваплылык белән караулары аерып тора.

– Менә шуңа басым ясарга кирәк тә! Яшьләрнең уңышка ирешәселәре, сәламәт, матур буласылары килә. Әгәр наркотиклар кулланасың икән, моңа ничек ирешеп була соң? Аларга иялашкан очракта син нәрсә югалтачаксың? Менә шундый фикерләрне яшьләргә сеңдерергә, аларның үзләрендә әлеге әчке карарның өлгереп җитүенә булышырга кирәк.

«Наркотикларсыз клуб тормышы» проекты яңарыш ягына көчле этәргеч алыр, ул тагын да нәтиҗәлерәк эшләр, ә Татарстан яшьләренең ялы тагын да сәламәтрәк һәм куркынычсызрак булыр дип ышанасы килә.

Катерина КОТОВА.

«ЗАО «Камдорстрой Автобаза-48» требуются водители кат. С, D, Е, машинисты автокрана. Вахтовый метод, з/п сдельная.
Тел.: 8-950-311-29-11, 8-906-117-15-12 (водители), 8-919-632-58-60 (автокрановщики), (8552) 46-67-18
РЕКЛАМА

ИГЪЛАННАР, БЕЛДЕРҮЛӘР

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ О СОГЛАСОВАНИИ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Алкиным Марселем Ревовичем, 422330, РТ, Кайбицкий район, с. Старые Чечкабы, ул. Советская, д.50, aaa89179118990@mail.ru, 89179118990, кв. атт. № 16-11-391.

В отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:220456:2, расположенного Республика Татарстан, г Казань, Авиастроительный район, ул Поперечно-Астраханская, дом 35, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границы и площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Зарипова Ф.Р., Республика Татарстан, г. Казань, улица Маршала Чуйкова, дом 89, кв.110, т. 89534124801.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: РТ, г. Казань, ул. В. Кулагина, д.10, оф.224. 29 мая 2017г. в _8_ часов _30_ минут.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: РТ, г. Казань, ул. В. Кулагина, д.10, оф.224. Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 28 апреля 2017г. по 29 мая 2017г. по адресу: РТ, г. Казань, ул. В. Кулагина, д.10, оф.224.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы: 16:50:220456:47(РТ, г Казань, Приволжский район, ул. Беломорская, д. 37 а), 16:50:220456:6 (РТ, г. Казань, ул. Поп.-Астраханская, д 33.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяюший личность, а также документы о правах на земельный участок. Ваша явка или явка Вашего представителя с доверенностью, подтверждающей его полномочия участвовать в установлении границ земельного участка и подписывать соответствующие документы, необходима. Ваше отсутствие или отсутствие Вашего представителя не является препятствием для проведения работ по согласованию границ земельного участка.

Состоится собрание собственников и пользователей овощехранилища по адресу г. Казань, с/т «сад 7 КМПО» Собрание состоится 7 мая 2017г, возле самого овощехранилища. Повестка дня: 1). Субботник, 2) О выделении в натуре, мою 1/120 доли в общей долевой собственности, в здании овощехранилища, ячейка №64. Морозова Н.А.89033889918

Чайнворд

«Тукай – бөек татар шагыйре»



Нияз Бишбалта төзеде.

Җаваплар.
1.Буран **2.**Насыйхәт **3.**Теш **4.**Шөһрәт **5.**Тормыш **6.**Шагыйрьгә **7.**Әхлаксызлык **8.**Кошчык **9.**Китмибез **10.**Золым **11.**Мәхбүс **12.**Сорыкортларга **13.**Алдандым **14.**Мәхәббәт **15.**Тәләһһеф.

1.
Тик кенә торганда капланды томанга
бар һава;
Кар оча, кар себрелә,
кар котрына һәм кар ява.

2.
Күрмәгез берьяклы дип сез
бу вафасыз дөньяны;
Ул ике яклы: аның бардыр иләк
һәм күн ягы.

3.
Сине сөеп, шигырь сөйләп,
шагыйрь булып
Йөрүләрем бөтенләй ук нахак, имеш.

4.
Яз язу, ләкин кызыкма һичвакыт
шөһрәткә син;
Бик төренмә, иртәгүк артык
булыр чүпрәккә син.

5.
Авырлык төшсә, түз,
сер бирми-нитми;
Ни хәлләр яшь егеткә килми-китми?

6.
Гомердә син бу ат белән аталма,
Торып җирдән, сәмалардан ат алма.

7.
Бик югартын күз салырга
башладык әхлакка без,
Кер күңелдә күплегеннән
бармыйбыз ак якка без.

8.
Очып киткәндә ул шундый
матурлап сайрады моңлы:
Миңа санки азат иткән өчен
изге дога кылды.

9.
Кара йөзләр безне булмас эшкә
тәклиф иттеләр:
– Сезгә монда юк ирек,
солтан җиренә кит, – диләр.

10.
Фәкыйрь кеше! Кемнәр сиңа
иман таккан?
Тәзкирәңә мөслим диеп, игълан таккан?

11.
Утырам мин тимер читлек эчендә,
Каты кайгы, ачы хәсрәт эчемдә.

12.
Яза күрмә, җитәр, артык, Тукаев,
вастрок бар бит;
Куярлар астырып дарга,
ятып тор бер дә кузгалмый.

13.
Кич мине, мин башны бөкмим,
мин үземчә зур хәзер;
Син дә бер мәгърурә булсаң,
мин дә бер мәгърур хәзер.

14.
Җир яшәрмәс, гөл ачылмас –
төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь,
булмаса илһамчысы.

15.
Шаккатабыз тышкы зиннәтләр,
киемнәргә карап;
Җан сатабыз әллә нинди вак
«тиеннәргә» карап.

Казан ипподромында гольф һәм пейнтбол уйнарга көтәләр

«Казан» Халыкара ат-спорт комплексы киңкырлы эшчәнлек алып бара. Спорт мәйданчыгы ат спортына гашыйкларны үзенә җәлеп итеп кенә калмый, биредә комплекс буйлап кызыклы экскурсияләр дә оештырыла, пейнтбол клубы эшли, өсте ябулы футбол кыры да бар.

28 апрель көнне 13.00 сәгатьтә ипподромда тантаналы төстә ат чабышы сезоны ачыла.

– Бу көнне уникe старт планлаштырылган. Әйтик, чиста токымлы атлар өчен – дүрт, гарәп токымлы атлар өчен – ике бәйге. Мәскәү, Самара, Оренбург, Пенза, Татарстан, Мари Эл, Башкортстаннан килгән спортчылар арасында иң көчлеләр һәм җитезләрне ачыклаячаклар. Гомуми приз фонды 500 мең сумнан да артып китә, – ди «Казан» Халыкара ат-спорт комплексының үсеш бүлеге башлыгы **Динә Галләмшина.**

Ат чабышларына кадәр ипподром белән танышуны комплекс буйлап экскурсиядән башларга була. Европада иң зур, ә Россиядә мондый дәрәҗәдәге бердәнбер булган ипподром төрледән-төрле зоналарны берләштерә. Шуңа күрә дә ул Казанның туристик маршрутларына кертелгән.

90 гектардан артык мәйданны биләгән комплекс берьюлы 6 мең тамашачыны кабул итәргә сәләтле, димәк, мондый зур корылма белән идарә итүнең үз серләре бар дигән сүз. Биредә кунаклар ат үрчетү һәм ат спорты музеена керә ала.

Бахбайлардан башка нинди ипподром инде ул – программага ат абзары буйлап экскурсия дә керә. Аларны тәм-том – коры вак клиндер, алма, кишер, шакмаклы шикәр белән сыйларга ярый.

– Зур ярышлар үткәрелгән вакытта бахбайларны 42 төбәктән китерәләр. Бу, нигездә, Президент призына уздырыла торган бәйгеләр вакытында була. Ә гадәти көндә Россиянең 20-25 төбәгеннән китерелгән атлар биредә даими яши, бары тик чабышкыларны гына кыш чыгарга көньякка алып китәләр. Чечня, Кабарда-Балкария, Карачай-Чиркәс, Ставрополь, Краснодар, Ростов, Самара, Сарытау юртаклары – ел әйләнәсе Казанда, ә Ульяновск, Мәскәү аргамаклары ярышлар вакытында китерәләр. Күршеләребездән Чуашстан, Мари Эл, Удмуртия республикаларын, Киров өлкәсен санап үтәргә мөмкин, – ди «Казан» Халыкара ат-спорт комплексы директоры **Сергей Василенко.**

Ипподромда теләгән кешегә шулай ук атка атланып йөрү мөмкинлеге дә тәкъдим ителә: профессиональ инструкторлар сезне ияргә дөрес утырырга өйрәтәчәк. Әгәр ат спорты белән чын-чынлап мавыгып китсәгез, профиль мәктәбе эшли. Әзерлек курслары ике елдан биш елга кадәр дәвам итә. Моннан тыш, ат-спорт комплексы территориясендә иппотерапия үзәге, өсте ябулы футбол кыры, «Хан» спорт көрәшләре клубы эшли. Комплекс территориясенең ел әйләнәсе буш торганы юк. Мисал өчен, Яңа ел бәйрәмнәрендә «Хан ишегалды»нда Кышкы Сабан туе үткәрделәр, кунакларны атларда һәм этләр җигелгән чаналарда утыртып йөрттеләр, ачык шугалак эшләде. Күптән түгел генә ат-спорт комплексында Нәүрүз бәйрәме гөрләп узды.

Ипподромның быелгы җәйгә дә планнары зурдан.

– Төрледән-төрле күргәзмәләр эшләячәк, бездә семинарлар, тренинглар, корпоративлар һәм туйлар үткәрү өчен дә бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Моннан тыш, җәен гарәп атларында ике Халыкара бәйге үткәрү күздә тотыла. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре ел дәвамында дөньяның җиде-сигез иң яхшы ипподромында гарәп аргамаклары катнашында чабышлар уздыра, чыгымнарны да тулысынча үзе күтәрә. Россиянең бер генә төбәгендә дә болай эшләмиләр, бары тик бездә генә. Ипподромны шулкадәр ошаттылар, күрсәең, хәзер инде ике бәйге оештырырга булдылар, – дип өсти Сергей Василенко.

Моннан тыш, тиздән ат-спорт комплексы территориясендә ике пейнтбол мәйданчыгы барлыкка киләчәк. Аларның берсе ачык булыр дип көтелә, ә икенчесен кышкы сезонга өсте ябулы итеп төзиләр. Гольф кырында да эшләр ахырына якынлаша, биредә чирәм җәясе, кечкенә чокырлар ясыйсы гына калган. Ипподром башлыгы раславынча, комплекс иң башта ук ат яратучылар өчен генә түгел, ә барлык казанлыларны үзенә тартып тору үзәге буларак төзелгән.

Реклама

АФИША
1-7 МАЙ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

3 май «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум
4 май Наил Дунаев юбилей кичәсе
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум
5 май «Әрем исе» (И.Зәйниев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
6 май «Диләфрүз – Remake» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
6 май «Афәрин, артист!» (Р.Харис)
Буа татар дәүләт драма театры
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 500 сум
6 май «Ак калфагым төшердем кулдан» (И.Юзеев)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

2 май «Алтын көз» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин)
Башлана: 18.30
3 май «Беренче мәхәббәт» (И.Гали)
Башлана: 18.30
4 май «Без – кырык беренче ел балалары» (М.Мәһдиев)
Башлана: 12.00
4 май «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов)
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 300-1000 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

1 май «Волшебник изумрудного города» (А.Волков)
Башлана: 11.00, 13.00
1 май «Не хочу, не буду»
Башлана: 15.00
4 май «Ханума»
Башлана: 18.30
Гастроли Тольяттинского театра кукол «Пилигрим»
6 май «Каштанка» (А.Чехов)
Башлана: 11.00, 13.00
7 май «Каштанка» (А.Чехов)
Башлана: 11.00, 13.00
7 май «Муха-Цокотуха» (К.Чуковский)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 250-600 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
Керү ирекле (эш көннәрендә). 5+

Газетабызның киләсе саны 4 майда чыга.

tatar-inform.ru

«Рубин» кабат оттырды

26 апрель көнне Казанның «Рубин» футболчылары, Россия чемпионатының 25нче туры кысаларында, Грозныйның «Терек» командасы белән очрашкан иде. Ләкин туган якта үткәрелгән матч та безнең футболчыларга уңыш китермәде. Инде сигез уен рәттән казанлылар җиңү яулый алмый. Бу юлы да турнир таблицасы буенча уртача саналган «Терек» «Рубинга» бер гол кертүгә иреште.

Исегезгә төшерәбез, бу матч Казан халкы өчен тулысынча бушка иде. Билетларны «Рубин» хезмәткәрләре үз кесәләреннән түләде. Ләкин ни кызык, стадион яртылаш та тулмаган иде. Җанатарлар социаль челтәрләрдә: «Мондый футбол безгә бушка булса да кирәкми», – дип язган.

ФУТБОЛ. 1 май көнне Казанда Конфедерация Кубогына җанатар паспорты бирә торган тагын бер үзәк ачыла. Ул Четаев урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан. Шундый ук үзәк инде Бауман урамында уңышлы гына эшләп килә.

Җанатар паспорты алган кешеләргә 17 май көнне Россия чемпионатының 29нчы туры кысаларында «Казан-Арена» стадионында узачак «Рубин» – ЦСКА матчы да бушка булачак.

ШАХМАТ. Алисә Галләмова шахмат буенча Европа чемпионатында «бронза» медальгә ия булды. 24 апрель көнне Латвиянең Рига шәһәрендә үткәрелгән бәйгедә, барлыгы 11 очкодан 8не җыеп, өченче урынга чыкты. Бәйгедә 144 шахматчы катнашкан иде.

АТ ЧАБЫШЛАРЫ. Бүген Казан ипподромында ат чабышлары сезоны ачыла. Барлыгы 12 старт көтелә: чабышларның дүртесе – чиста токымлы атлар, икесе гарәп токымлы атлар арасында була. Спортчылар Мәскәү, Мари Эл, Башкортстан, Самара, Оренбург, Пенза өлкәсеннән килә. Чабышлар көндезге бердә башлана.

СУ ПОЛОСЫ. 25-30 апрельдә Казанда су полосы буенча Россия Кубогы ярышлары башлана. Әлеге чара республикада инде икенче тапкыр оештырыла. Ярышлар «Оргсинтез» белән Су спорты төрләре сараенда узачак. Безнең «Синтез» Волгоград шәһәренең «Спартак» командасы белән көч сынаша.

5мәзәк

– Вәли, син бүген бик көяз күренәсең, әллә берәр бәйрәмме?
– Әйе, алтын туемны билгеләп үтәм.
– Ничек алтын? Синең өйләнгәнеңә биш кенә ел бит!
– Ул елларның һәркайсысы ун елга тора!

***

Ире өенә исерең кайта.
– Нигә шулкадәр күп эчтең? – дип сүгә аны хатыны.
– Күп түгел, хатын, һәрвакыттагыча, өч кешегә бер ярты.
– Ә нигә шундый кыяфәткә төштең?
– Тегеләр килмәде.

***

Яшь инспектор кызыл утка чыгып киткән машина хуҗасын туктата:
– Документларыгыз!
– Иптәш сержант, дусларда онытып калдырганмын. 300 грамм аракы эчкән идем – бөтенесе баштан чыккан.
Инспектор начальнигы янына йөгереп килә:
– Иптәш лейтенант, анда исерек шофер, житмәсә документлары да юк!
Лейтенант теге шофер янына килә:
–Йәле, әрәп кара... Юк, исерек түгел. Документлары да бар. Ә нишләп сине сержант, исерек һәм документлары юк, диде?
– Сез аны күбрәк тыңлагыз. Әле ул сезгә кызыл утка чыгып китте дип тә әйтер.

***

– Кайсыгыз әйтә: җан тәннән аерыла аламы? – дип сорый мулла шәкертләрдән.
– Ала, – дип җавап бирә арадан берсе.
– Дәлилллә.
– Кичә караңгы төшкәч сезнең өй буеннан узып барганда, мин тәрәзәдән мондый сүзләр ишеттем: «Әә хәзер, җаным, киен дә сыптыр тизрәк!»

***

– Вәли, малайлар белән сугышма дип мин сиңа ничә тапкыр әйттем?!
– 19 тапкыр.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1642. Гомуми тираж – 6179.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 707. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы